Эксперимент

МАТЕМАТИКА

3

Ф. Г. Казыйханова, В. С. Казыйханов

МАТЕМАТИКА



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ



479
x 305
2395
+ 1437
146095
1281
x 25
6405
+ 2562
32025
162
x 109
1458
+ 162
17658
12
?
20
5
9
?
?
16
27
3 см
4 см
5 см
? см
6
7
1
6
6
2
6
8
2

Ф. Г. Казыйханова
В. С. Казыйханов

МАТЕМАТИКА

ДҮРТЬЕЛЛЫК БАШЛАНГЫЧ ТАТАР МӘКТӘБЕНЕҢ
3 НЧЕ СЫЙНЫФЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдиме белән
сынап карау өчен бастырыла

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1 : 51*03
ББК 22.1 я71
К16

Рәссамы *Р. А. Сәйфуллина*

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Укытучылар игътибарына!

Бу дәреслек белән эшләү өчен, Ф. Г. Казыйханова, В. С. Казыйхановның «Математика дәреслеге белән ничек эшләргә. 3 нче сыйныф. Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

«Мәгариф» нәшрияты чыгарган методик кулланмаларны сатып алу өчен, түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итәргә: 420111. Казан шәһәре, Бауман урамы, 19 нчы йорт, 312 нче бүлмә.

Казыйханова Ф. Г.

К16 Математика: Дүртьеллык башл. татар мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек/ Ф. Г. Казыйханова, В. С. Казыйханов.— Казан: Мәгариф, 2005.— 136 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1502-7

ISBN 5-7761-1502-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2005
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

1 1000 ЭЧЕНДӘ ГАМӘЛЛӘР (КАБАТЛАУ)

1

Саннарны укы.
853, 381, 418, 85, 80.
Бу саннарда 8 цифры нәрсәне белдерә?

2

143, 506, 400, 780 саннарының һәркайсында ничә берәмлек, дистә һәм йөз бар?

3

731 дән 742 гә кадәр барлык саннарны яз.

4

3 һәм 4 цифрларын гына кулланып, барлык икеурынлы саннарны яз. Шул саннарның суммасын тап.

5

1,5,4 цифрлары белән барлык өчурынлы саннарны яз. Цифрлар кабатланмасын.

6

Саннарны цифрлар белән яз.
Туксан алты, өч йөз сигез, җиде йөз кырык биш, җитмеш өч, егерме ике.

7 Таблицада язылган саннарны укы.

Йөзләр	Дистәләр	Берәмлекләр
III разряд	II разряд	I разряд
1	6	9
8	8	5
2	0	3
3	4	0
	0	3

8 Саннарны разрядлар таблицасына яз.
247, 308, 530, 200, 42, 6.

9 Саннарны цифрлар белән яз.

5 йөз 1 дистә 3 берәмлек
2 йөз 2 дистә 2 берәмлек
7 йөз 4 берәмлек
6 йөз 9 берәмлек

10 Саннарны яз һәм укы:
өченче разрядта 9, икенче разрядта 7, беренче разрядта 5 берәмлек;
беренче разрядта 7, икенче разрядта 3, өченче разрядта 1 берәмлек.
Разрядларның уңнан сулга саналганын искә алдыңмы?

11 Саннарны яз. Алардан соң килгән саннарны ата.

8 дистә 8 берәмлек
8 йөз 8 берәмлек
8 йөз 8 дистә 8 берәмлек
8 йөз 8 дистә

12 5 цифрын рәттән өч тапкыр яз. Килеп чыккан санда һәр цифр нәрсәне белдерә?

13 Таблицада кушу гамәле башкарылган.

III разряд	II разряд	I разряд
йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
+ 9	0 2	0 0 5
9	2	5

III разряд	II разряд	I разряд
йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
+ 1	0 6	0 0 7
1	6	7

900 + 20 + 5 = 925   100 + 60 + 7 = 167

Тигезлекләрдәге 900, 20, 5 һәм 100, 60, 7 саннары ничек атала?

14 Саннарны разряд кушылучылары суммасы белән яз. 246, 78, 308, 840, 438.

15 Сумманы исәплә.

300 + 20 + 3   400 + 2
200 + 5   20 + 7
500 + 30   100 + 10 + 1

16 Сантиметрларда күрсәт.

3 м 13 см   5м 30 см
6 м 4 см   6 м

17 9, 99, 999 саннарының алдыннан һәм артыннан килгән саннарны яз.

18 Сантиметрларда күрсәт.

6 дм 4 см   1 дм   42 дм 3 см   36 дм

19 Санлы турыда 3, 5, 7, 9 саннарын билгеләә. 9 саныннан 3 берәмлек ераклыгындагы саннарны билгеләә. 9 дан уңдарак нинди сан билгеләнде? 9 дан зуррак саннар аның кайсы ягында урнашкан?

20 Бирелгән ике санның кайсысы санлы турыда сулдарак урнашкан?

202 яки 210   87 яки 78

151 яки 115   998 яки 989

21 Саннарны чагыштыр. < тамгасы белән тигезсезлек яз.

224 һәм 242   505 һәм 504

578 һәм 758   104 һәм 204

22 Саннарны чагыштыр. > тамгасы ярдәмендә тигезсезлекне яз һәм укы.

363 һәм 336   105 һәм 107

456 һәм 465   86 һәм 68

23 Чагыштыр. Күп нокталар урынына тиешле тамга куй.

4 м ... 400 см   4 м 63 см ... 436 см

298 см ... 3 м   7 м 03 см ... 730 см

6 дм ... 62 см   34 дм ... 304 см

24 * урынына нинди цифрлар куйганда, тигезсезлек дөрес була?

57 < 357   62 > 626   36* > 365   *14 < 514

25 ? билгесе урынына саннар яз. Ялгышма!



26 Натураль саннарны кушуны 7 + 5 = 12 мисалы ярдәмендә санлы турыда күрсәт. Кушылучыларны һәм сумманы дугалар белән билгелә.

27 Мисалларны чиш.

52 + 18 114 + 56 570 + 27
67 + 23 302 + 98 92 + 508

28 Беренче көнне — 57 га, икенче көнне 17 га га артыграк җир сөрелгән. Ике көндә ничә гектар җир сөрелгән?

29 Бер басудан — 200 т, икенчесеннән 91 т га артыграк бәрәңге уңышы алынган. Барысы ничә тонна уңыш җыелган?

30 20 гә нинди саннарны кушсаң, берәмлекләрне аңлаткан цифр гына үзгәрә, ә дистәне аңлатканнары үзгәрми?

31 Исәпләгәндә кушуның нинди үзлеген файдалану уңайлы? Исәплә.

51 + 349 31 + 109 8 + 32 28 + 640

32 Исәплә.

152 + 143 + 48 + 57
19 + 18 + 17 + 13 + 12 + 11

Исәпләгәндә кушуның нинди үзлекләреннән файдаландың?

33 Мисалларны чиш.

0 + 142 108 + 0 63 + 7 + 0
62 + 0 143 + 0 + 57 168 + 0 + 2

34 Гамәлләрне башкармыйча гына суммада ничә цифр булуын билгелә.

$$\begin{array}{r}+\begin{array}{r}358\\ \underline{243}\end{array}\end{array} \quad \begin{array}{r}+\begin{array}{r}642\\ \underline{\ 91}\end{array}\end{array} \quad \begin{array}{r}+\begin{array}{r}605\\ \underline{495}\end{array}\end{array} \quad \begin{array}{r}+\begin{array}{r}143\\ \underline{895}\end{array}\end{array}$$

35 Баганалап язып исәплә.

444 + 366 108 + 398 102 + 48
645 + 98 200 + 799 700 + 77

36 Һәр пардагы саннар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла? Пардагы саннарның суммасын тап.

27 һәм 72 18 һәм 28
19 һәм 91 36 һәм 37

37 Бер тартмада 22 кг помидор бар. Икенчесендә 8 кг га кимрәк. Ике тартмада ничә килограмм помидор бар?

38 Хәлил бер сан уйлады. Шул санга 23 не кушсаң, 51 була. Уйланган санны тап.

39 Һәр баганадагы аңлатмалар нинди кагыйдәгә буйсына? Һәр баганадагы мисалларга өстәп, 2 шәр аңлатма яз. Исәплә.

77 – 70	73 – 5
76 – 60	74 – 6
75 – 50	75 – 7

40 Бирелгән саннарны гына файдаланып, 4 аерма яз. Саннарның аермасы 18 гә тигез булсын.
30, 16, 34, 48, 23, 37, 19, 41.

41 Кимүчесе — 28, кыйммәте 10 нан кечерәк булган өч аерма яз.

42 Баганалап язып исәплә.

810 – 444	506 – 108	150 – 102
743 – 645	999 – 799	777 – 700

43 Күп нокталар урынына тиешле сүз куй.
Саннарны кушу нәтиҗәсе шул саннарның ... дип атала.
Бер саннан икенче санны алу нәтиҗәсе, шул саннарның ... дип атала.

44 Һәр санда ничә йөз, дистә, берәмлек бар?
196, 205, 460, 106, 242.

45 Исәплә.

245 + 308   264 + 408   527 − 349
167 + 312   642 − 26   704 − 369

46 Разряд кушылучылары суммасы ярдәмендә яз.
318, 603, 640, 81.

47 Аңлатма яз.
18 саны 10 нан 8 гә зуррак.

48 Беренче көнне 254 га җирдән уңыш җыелган. Бу икенче көндәгегә караганда 62 га га кимрәк. Ике көндә ничә гектар җирдән уңыш җыелган?

49 «Тапкырчыгыш рәвешендә күрсәтегез» дигән сүзләр урынына «тапкырлаучыларга таркатыгыз» дип әйтәләр.
6, 8, 13, 20, 81 саннарын ике тапкырлаучыга таркат.

50 18 санын төрле юллар белән ике тапкырлаучыга таркат.

51 Кайсы саннарны ике тигез тапкырлаучыга таркатып була?
9, 25, 20, 18, 81, 64.

52 Тапкырчыгышларның кайсысы зур икәнен тапкырлауны чишмичә генә әйт.

137 · 43 яки 137 · 62
255 · 146 яки 258 · 146

53 Баганалап язып тапкырла.

78 · 3 142 · 4 308 · 5
123 · 31 105 · 42 216 · 23

54 Бер банкага 4 кг бал сыя. Шундый ук 6 банкада ничә килограмм бал булыр?

55 Гамәлләрне башкаруның уңайлы тәртибен сайлап исәплә.

53 · 2 · 5 25 · 3 · 4 50 · 3 · 2

56 Түгәрәк саннарны (нульгә тәмамланган саннар) тапкырлау өчен, тапкырлауның үзлекләрен файдалан.

20 · 30 60 · 4 40 · 20

57 54 санының уң ягына бер нуль өстәп язсаң, сан ничә тапкыр зурая? Ике нуль өстәсәң?

58 27, 64, 8 саннарының һәркайсын өч тигез тапкырлаучыга таркатып яз.

59 Кыйммәте 80 гә тигез булырлык итеп, * урынына гамәл тамгалары куй.

20 * 4   120 * 40   80 * 0
40 * 40   40 * 2   80 * 1

60 Аңлатманың кыйммәтен тап.

$0 \cdot 87$ $1 + 49$ $1 \cdot 55$
$0 + 48$ $49 \cdot 1$ $89 \cdot 0$

61 Исәплә.

$(30 + 1) \cdot 7$ $3 \cdot (50 + 7)$ $(20 - 1) \cdot 8$
$(40 + 2) \cdot 6$ $(50 - 2) \cdot 4$ $5 \cdot (20 - 3)$

62 Тарату үзлеген кулланып, тапкырчыгышны тап.

$81 \cdot 7$ $43 \cdot 6$ $39 \cdot 3$
$69 \cdot 5$ $64 \cdot 4$ $41 \cdot 9$

63 Исәплә.

$36 \cdot 9 + 64 \cdot 9$ $154 \cdot 4 - 54 \cdot 4$
$43 \cdot 7 + 57 \cdot 7$ $9 \cdot 3 + 81 \cdot 3$

64 Наил бер сан уйлаган. Бу санга 3 не кушып, 5 кә тапкырласаң, 50 була. Наил нинди сан уйлаган?

65 21 саны белән билгесез санның аермасын 4 кә тапкырласаң, 40 килеп чыга. Шул санны тап.

66

∗ урынына төшереп калдырылган цифрларны куй.

$$\begin{array}{r} \times \begin{array}{r} 1{*}2 \\ 2{*} \end{array} \\ \hline + \begin{array}{r} {*}92 \\ {*}{*}{*} \end{array} \\ \hline {*}{*}{*}{*} \end{array} \qquad \begin{array}{r} \times \begin{array}{r} 163 \\ {*}{*} \end{array} \\ \hline + \begin{array}{r} {*}52 \\ {*}26 \end{array} \\ \hline {*}{*}{*}{*} \end{array}$$

67

6 м тукымадан 2 күлмәк теккәннәр. 18 м тукымадан шундый ук ничә күлмәк тегеп була?

68

Әбисенә 56 яшь. Ул оныгыннан 8 тапкыр олырак. Оныгына ничә яшь?

69

Исәплә.

0 : 9	6 : 1	81 : 9	54 : 9	9 : 0
0 : 24	69 : 1	72 : 9	63 : 9	42 : 0

70

Таблицаны тутыр.

a	32	48	64	16	24
b	8		8		8
$a : b$		6		2	

71

Бүленүчесе 12. Өлештә 1, 2, 3, 4, 6, 12 килеп чыгарлык итеп, тигезлекләр яз.

72 Һәр санны 7 тапкыр кечерәйт.

14, 28, 49, 63, 21, 35, 42.

73 Бүлү гамәлен башкар.

50 : 7	82 : 9	66 : 8	27 : 5
28 : 5	39 : 6	44 : 8	64 : 8

74 Исәпләүдә нинди хата киткәнен аңлат.

41 : 5 = 7 (калдык 6)   37 : 6 = 5 (калдык 7)

75 Калдыклы бүлүне башкар. Дөреслеген тикшер.

63 : 8   70 : 9   58 : 6   45 : 7

76 Бүленүчене тап.

Бүлүче 9, өлеш 8, калдык 3.
Бүлүче 8, өлеш 7, калдык 4.
Бүлүче 7, өлеш 5, калдык 5.

77 Мин уйлаган санны 6 га тапкырлап, 3 не кушсаң, 51 була. Мин нинди сан уйлаганмын?

78 x ка нинди кыйммәт биргәндә, тигезлек дөрес була?

$8 : x = 8$	$x : 1 = x$	$0 : x = 0$
$x : 7 = 1$	$x : 3 = 0$	$x : 0 = 2$
$1 : x = 1$	$x : x = 1$	$x : 0 = 25$

79 Җөмләләрне тигезләмә рәвешендә яз һәм x ны тап.

x белән 48 нең суммасы 102 гә тигез.
705 белән x ның аермасы 258 гә тигез.
x белән 9 ның тапкырчыгышы 27 гә тигез.
x ны 8 гә бүлгәндә чыккан өлеш 7 гә тигез.

80 x ның бөтенме, өлешме икәнен билгелә. x ны тап.

$345 + x = 145$ $\quad$ $8 \cdot x = 72$
$x - 158 = 446$ $\quad$ $54 : x = 9$

81 Билгесез компонентларны ничек тапканыңны аңлат.

$32 : x = 8$ $\quad$ $8 \cdot x = 48$ $\quad$ $x + 42 = 105$
$x : 7 = 7$ $\quad$ $8 \cdot 91 = x$ $\quad$ $x - 78 = 92$

82 Мәсьәләне тигезләмә төзеп чиш.
Рәсимә бер сан уйлады. Шуңа 12 не кушып, килеп чыккан суммадан 27 не алгач, 68 булды. Рәсимә нинди сан уйлаган?

83 Тигезләмә төзеп чиш.

Нинди санны 32 гә киметсәң, 103 була?
Нинди санны 9 тапкыр киметсәң, 10 була?
Нинди санны 8 тапкыр арттырсаң, 48 була?
Нинди санны 72 гә арттырсаң, 243 була?

84 Тигезләмәләргә туры килерлек итеп, мәсьәлә төзе.

$x + 143 = 647$ $643 - x = 245$

85 Мәсьәләләрдәге охшашлыкны һәм аерманы тап.

1) Гаражда 6 җиңел машина бар. Йөк машиналары 2 гә күбрәк. Гаражда ничә йөк машинасы бар?
2) Гаражда — 6 җиңел машина, 8 йөк машинасы бар. Гаражда барысы ничә машина бар?
3) Гаражда 6 җиңел машина бар. Йөк машиналары 2 гә күбрәк. Гаражда барысы ничә машина бар?



86 Ике мәсьәләдән бер мәсьәлә төзе: беренче мәсьәләнең шартына икенче мәсьәләнең соравын куй.
1) Ринатның 12 шакмаклы дәфтәре бар. Сызыклылары 3 кә азрак. Ринатның ничә сызыклы дәфтәре бар?
2) Ринатның 12 шакмаклы, 9 сызыклы дәфтәре бар. Ринатның ничә дәфтәре бар?



87

Мәсьәләне чиш.

Беренче киштәдә — 16 китап, икенче киштәдә беренче киштәдәгегә караганда 7 китапка азрак, өченче киштәдә икенчедәгедән 3 китапка күбрәк. Өч киштәдә барысы ничә китап бар?

Кыскача язу:

I 16 к.
II ? к. 7 к. <
III 3 к. >
} ?

Кисемтәле модель.





88

Югарыдагы бирем үрнәгендә мәсьәләне кыскача яз, кисемтәле моделен һәм схемасын төзе.
Арыш 90 га мәйданга чәчелгән. Бодай арыштан 30 га га артыграк, солы бодайдан 23 га га азрак мәйданга чәчелгән. Барысы ничә гектар җиргә ашлык чәчелгән?

2 К 5/270

89 Сызым буенча өч гади, бер төзелмә мәсьәлә төзе.



90 Кыскача язу буенча мәсьәләне чиш.

	Булган	Китерделәр	Булды
I	64	?	196
II	2 тапкыр ким		

91 Кыскача язу куллан.
Беренче сыйныф укучылары — 12 уенчык, икенчеләр беренчеләрдән 6 уенчыкка күбрәк ясаганнар. Әгәр өченчеләр алардан 2 тапкыр күбрәк уенчык ясаган булсалар, укучылар барысы ничә уенчык ясаган?

92 Кисемтәле модель яса.
Бер кибеткә — 302 кг, икенчесенә — 125 кг, өченчесенә беренчесеннән 58 кг га күбрәк икмәк китерделәр. Өч кибеткә күпме икмәк китергәннәр?



93 Тигезләмә төзеп чиш.
Буш автобуска 24 кеше керде. Икенче тукталышта 11 кеше чыкты, берничә кеше керде. Автобуста 30 кеше булса, тукталышта автобуска ничә кеше кергән?

94 Кыскача язуы буенча мәсьәләнең кисемтәле моделен эшлә.

I 25
II ? 5 кә >
III ? 12 гә <
} ?

95 Кисемтәле моделе буенча мәсьәләне кыскача яз.



96 Мәсьәләне чиш.
Кибеттә 3 көндә 800 кг шикәр сатылды. Беренче көнне — 200 кг, икенче көнне беренче көндәгедән 2 тапкыр артыграк шикәр сатылды. Өченче көнне күпме шикәр сатылган?

97

Исәплә.

$92 \cdot 8$ $63 \cdot 8$
$14 \cdot 7$ $26 \cdot 5$

98

Исәплә.

$0 \cdot 43$ $62 \cdot 1$ $64 : 8$ $27 : 1$
$1 \cdot 57$ $21 \cdot 0$ $32 : 4$ $27 : 3$

99

Аңлатмаларның кыйммәтен тап.

$18 \cdot 20 - 11 \cdot 20$ $56 \cdot 28 - 56 \cdot 18$
$64 \cdot 10 + 36 \cdot 10$ $43 \cdot (10 - 1)$

100

Тигезләмәләрне чиш.

$5 \cdot x = 50$ $81 - x = 9$
$42 : x = 6$ $x - 7 = 23$

101

Калдыклы бүлүне башкар.

$46 : 9$ $65 : 8$ $46 : 5$
$27 : 4$ $83 : 9$ $34 : 8$

102

Беренче сан икенчесеннән 3 тапкыр кечерәк. Беренче санга 12 не кушкач, икенче сан килеп чыга. Бу саннарны тап.

2 КҮБУРЫНЛЫ САННАР

103 Таблицаны беренче багана үрнәгендә тутыр. Саннарны укы.

1	3	7	9
10	30	70	90
100			
1 000			
10 000			
100 000			
1 000 000			

104 Саннарны укы.

Миллионнар классы (өченче класс)			Меңнәр классы (икенче класс)			Берәмлекләр классы (беренче класс)		
йөз	дистә	бер.	йөз	дистә	бер.	йөз	дистә	бер.
			1	4	8	3	8	1
				1	5	6	7	8
		4	2	5	8	1	9	6
	4	5	0	0	0	1	6	7
				1	6	0	0	1

105 Иң зур алтыурынлы һәм иң кечкенә җидеурынлы саннарны яз.

106 Саннарны классларга бүл һәм укы.

25 348   356 748   43 605   1 245 763

107 Саннар язылышында 3 цифры нәрсәне белдерә?

31 467   53 600   41 328   43 653

108 Саннарны укы.

3 000 142   3 148 000   642 105   4 160

109 Саннарны цифрлар белән яз:
җиде миллион ике йөз унбер мең биш йөз илле;
алты йөз мең тугыз йөз кырык алты;
сигез мең сигез;
җитмеш өч миллион җитмеш тугыз;
биш миллион биш мең биш йөз биш.

110 7 цифрын рәттән җиде тапкыр яз һәм килеп чыккан санны укы.

111 148 санын рәттән өч тапкыр яз һәм килеп чыккан санны укы.

112 Цифрлар белән яз.

биш мең   сигез йөз
алты миллион   алты миллион сигез йөз

113 Бирелгән саннардан алда һәм артта килгән саннарны яз.

1 000 5 000 9 999 11 111

114 Түбәндәге саннар арасындагы саннарны яз.

3 998 һәм 4 004 2 634 һәм 2 644

115 46 789 санын разряд кушылучылары суммасы белән яз. Санның цифрлары суммасын тап.

116 Берәмлекләр классының разрядларын ата. Меңнәр классының разряд исемнәрен әйт.

117 Телдән исәплә. Ничек исәпләгәнеңне аңлат.

40 000 + 7 000
15 000 – 5 000
8 800 – 800
642 000 – 42 000
400 000 + 60 000
506 000 – 6 000

118 Аңлатмаларның кыйммәтен тап.

564 – 142 + 140
786 – 14 + 14
158 + 142 – 42
666 + 344 + 999

119 Разряд кушылучылары суммасы белән нинди сан язылган?

50 000 + 3 000 + 400 + 70 + 4
400 000 + 20 000 + 3 000 + 600 + 40
80 000 + 400 + 50 + 2
700 000 + 700 + 7

120 Ике санның суммасы 374 кә тигез. Саннарның берсе 0 гә бетә. Шул нульне язмасаң, икенче сан килеп чыга. Саннарны тап.

121 Саннарны чагыштыр, * урынына >, <, = билгеләренең тиешлесен куй.

7 180 * 7 018	68 143 * 68 103
13 642 * 13 462	506 002 * 506 200

122 Натураль саннар рәтендә 3 999, 4 999, 9 999 саннарыннан соң килүче өч сан яз.

123 Чагыштыр.

2 222 * 22 222	3 003 * 3 300
2 002 * 2 202	40 004 * 40 040

124 xның тигезсезлек дөрес булырлык бер кыйммәтен тап.

$x < 985$	$x < 1\,000\,000$
$x > 1\,078$	$x > 999\,999$

125 * урынына куйганда, дөрес тигезсезлек килеп чыгарлык барлык цифрларны яз.

*3 > 13	564 > 5*8
1* < 18	13*4 > 1 353
1* < 11	10 < *1

126 Саннарны үсә бару тәртибендә урнаштырсаң, хикмәтле сүз укырсың.

1001	1011	1010	1101	1100	1110	1000	1111
и	ә	р	б	к	у	з	л

127 Сумманы исәплә.

2 351 + 6 329
23 073 + 56 975
683 506 + 314 131
297 623 + 2 375
7 065 + 3 048
81 607 + 26 067

128 Аерманы исәплә.

8 680 – 6 329
80 048 – 23 073
10 113 – 3 048
997 637 – 314 131
299 998 – 297 623
107 674 – 81 607

129 Гамәлләр тәртибен билгелә һәм аңлатмаларның кыйммәтен исәплә.

$23 \cdot 7 + 139 - 25 \cdot 4$
$(81 : 9 + 7 \cdot 3) \cdot 4$
$(243 - 234) \cdot 9 + 119$
$256 - (403 - 395) \cdot 7$

130 Алу гамәленә 3 мисал яз. Аерма кимүчегә тигез булсын.

131 72 кг борчак бар иде. 6 шар кг итеп, берничә пакетка салгач, 24 кг борчак калды. Ничә пакетка борчак салганнар?

132 Схема буенча аңлатма төзе. Аңлатманың кыйммәтен исәплә.



133 Саннарны цифрлар белән яз: унөч мең җитмеш сигез, алты мең тугыз, егерме мең сиксән ике, өч миллион егерме биш мең ике йөз өч.

134 Нинди сан таркатылган?

70 000 + 8 000 + 600 + 50 + 2
80 000 + 600 + 70 + 8
1 000 + 80 + 3

135 Саннарны чагыштыр.

2 803 * 3 028   11 011 * 10 101
33 303 * 33 330   4 206 * 4 260

136 Кушуны башкар.

7 894 + 1 056   83 272 + 45 678
22 348 + 6 602   80 000 + 18 950

137 Гамәлләрне башкар.

$289 - 4 \cdot (12 + 13) - 89$

$(643 + 6 \cdot 7 + 15) \cdot 10$

138 Ике киштәдә 34 китап булган. Әгәр бер киштәдән 14 китапны алсаң, киштәләрдәге китаплар саны тигез була. Һәр киштәдә ничәшәр китап булган?



139 Сумманы төрле ысуллар белән тап. Килеп чыккан саннарны чагыштыр. Кайсы ысул уңайлырак?

$16 + 8 + 4 + 12 + 20$

$(16 + 8) + (4 + 12) + 20$

$16 + (8 + 4) + (12 + 20)$

$(16 + 4) + (8 + 12) + 20$

140 Уңайлы ысул белән исәплә. Нинди үзлекләр кулланганыңны аңлат.

$203 + 92 + 8 + 97$

$143 + 117 + 57 + 83$

$31 + 260 + 40 + 69$

$43 + 44 + 45 + 46 + 47$

141 9 834 һәм 2 047 саннарының суммасын 1 881 гә кечерәйт.

142 Кушуны башкармыйча гына саннарның суммасын кыйммәтләре арту тәртибендә урнаштыр.

52 + 53   53 + 51   54 + 53   53 + 50   53 + 55

143 1, 2, 3, 4, 6, 7, 8, 9 саннарын буш шакмакларга яз. Саннар суммасының кыйммәте (һәр юлда, баганада, диагональ буйлап) 15 кә тигез булсын.

	5	

144 * урынына тиешле цифрларны яз.

$$\begin{array}{r} 42{*}6 \\ -\ 2{*}3{*} \\ \hline {*}572 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 7{*}32 \\ -\ 23{*}{*} \\ \hline {*}407 \end{array} \qquad \begin{array}{r} {*}81{*} \\ -\ 33{*}8 \\ \hline 3{*}62 \end{array}$$

145 Телдән исәплә.

1 дистә – 1
1 йөз – 1 дистә
1 мең –1 йөз
10 мең – 1 мең

10 дистә – 1
10 йөз – 1 дистә
1 мең – 1 йөз 1 дистә
10 мең – 1 мең 1 йөз 1 дистә

146 Аерманы тап.

540 − 38 1 000 − 100
700 − 152 1 000 − 638
3 000 − 781 4 000 − 295

147 Аерманы исәплә. Исәпләүнең дөреслеген кушу гамәле ярдәмендә тикшер.

8 003 − 947 50 000 − 6 009
2 000 − 496 4 300 − 55

148 6 200 һәм 639 саннарының аермасын 439 га арттыр.

149 Ничек исәпләгәннәр? Аңлат.

$6\,400 - 392 = 6\,400 - 400 + 8 = 6\,008$
$5\,890 - 789 = 5\,890 - 800 + 11 = 5\,090 + 11 = 5\,101$

150 Буш шакмакларга тиешле саннарны яз.

6	10	8	12
15	25	20	30
21	35		42
27		36	

151 Билгесез кушылучыны исәплә.

$381 + x = 510$
$x + 129 = 510$

152 k ны тап.

$479 + k = 608$
$k + 5\,954 = 6\,083$

153 Ял йортына беренче көнне 272 кеше килгән. Икенче көн азагына килүчеләр саны 401 булган. Икенче көнне ничә кеше килгән?

154 Фәнүзә бер сан уйлаган. Шуңа 122 не кушып, килеп чыккан суммага 97 не кушкач, 348 булган. Фәнүзә нинди сан уйлаган?

155 $146 + x + 254$ аңлатмасын гадиләштер. $x = 129$ булганда, кыйммәтен тап.

156 Иң кечкенә җидеурынлы, алтыурынлы, бишурынлы һәм өчурынлы саннарның суммасын исәплә.

157 x ны тап.

$x - 132 = 720$ $852 - x = 720$

158 k ны исәплә.

$k - 6\,789 = 132$ $\quad$ $8\,000 - k = 7\,868$

159 $658 + m - 526$ аңлатмасын гадиләштер. $m = 868$ булганда, кыйммәтен исәплә.

160 Шәһәр белән авыл арасы 408 км. Авылга кадәр 276 км юл калган булса, ничә километр юл үтелгән?

161 Фәһим бер сан уйлаган. Шул санга 305 не кушып, килеп чыккан суммадан 207 не алгач, 230 калган. Уйланган санны тап.

162 Иң кечкенә бишурынлы санның һәм иң зур өчурынлы санның аермасын исәплә.

163 3 төркемгә бүлеп яз.

13 м, 18 кг, 9 сәг, 68 м, 3 дм, 4 т, 32 ц, 64 ц 52 кг, 45 мин.

164 Бер үлчәү берәмлеге белән генә яз.

3 м 7 дм 3 см, 6 ц 31 кг, 2 кг 150 г, 3 сәг 20 мин, 2 сәг 5 мин, 3 км 95 м.

165 Суммаларны чагыштыр.

5 дм 3 см 2 мм + 2 дм 3 см 8 мм
532 мм + 238 мм

166 Суммаларны ике төрле ысул белән исәплә.

3 км 144 м + 2 км 856 м
7 т 608 кг + 1 т 392 кг
2 сәг 23 мин + 3 сәг 37 мин

167 20 м тукымадан 6 күлмәк теккәннәр. 60 м тукымадан шундый ук ничә күлмәк тегеп була?

168 Турыпочмаклыкның яклары 9 см һәм 4 см. Кисәкләрдән квадрат төзерлек итеп, турыпочмаклыкны ике тигез кисәккә бүл.

169 Чагыштыр.

2 км 150 м * 2 км 105 м
4 дм * 40 см

170 Бер үлчәү берәмлеге белән генә яз.

4 дм^2 3 см^2, 12 ц 3 кг, 3 кг 30 г,

5 м^2 20 дм^2, 5 га 142 м^2.

171 Аермаларны чагыштыр.

12 т 3 ц 15 кг – 3 т 2 ц 6 кг
12 315кг – 3 206кг

172 Аермаларны ике төрле ысул белән исәплә.

5 га – 1 478 $м^2$
8 т 2 ц –1 т 35 кг

173 Беренче кишәрлекнең мәйданы 157 га, бу икенчесенең мәйданыннан 19 гектарга зуррак. Ике кишәрлекнең мәйданы күпме?

174 Һәрберсе 12 шәр м лы 10 торбаны 3 әр м лы торбаларга бүлү өчен, ничә тапкыр кисәргә кирәк?

175 Гамәлләр тәртибен билгелә. Телдән исәплә.

32 : 4 – 40 : 5 + 54 : 6 + 11
(32 : 4 + 40) : 6 + 12
32 : (40 : 4 – 2) + 16

176 Исәплә.

163 248 + 361 642 – 856 · 7
68 368 – 1 243 · 5 + 161 847

177 $a = 8$ булганда, $191 \cdot a + 9$ аңлатмасының кыйммәтен тап.

178 Гамәлләрне башкар.

$(7\,000 - 4\,996) - 205 + 17\,993$

$4 \cdot (85 + 348) - 1\,033$

179 Турыпочмаклыкның буе 5 дм 2 см, иңе 3 дм 4 см. Периметрын исәплә.

180 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9 цифрларының кайберләре арасына кушу һәм алу тамгаларын куй. Килеп чыккан аңлатманың кыйммәте 100 гә тигез булсын.

181 Балалар 32 кг дару үләне җыйганнар. Шуларның 8 кг ы юкә чәчәге, ә кычыткан әремнән 6 кг га күбрәк булган. Балалар күпме кычыткан, күпме әрем җыйганнар?

182 Кибеткә 1 900 кап фломастер китерделәр. Карандашлар фломастерлардан 300 капка күбрәк. Кибеткә барысы ничә кап фломастер һәм карандаш китергәннәр?

183 Кыскача язып чиш.

Өч басудан 320 т ашлык җыеп алганнар. Икенче басудан — 70 т, икенче басу белән өченче басудан 245 т ашлык җыелган. Беренче һәм өченче басудан күпмешәр ашлык җыелган?

184 Кисемтәле модель ясап чиш.

Айрат — 28, Алмаз 16 балык тоткан. Айрат Алмазга ничә балыгын бирсә, аларның балыклар саны тигез була?

185 Схема ясап чиш.

Гаражда 20 машина бар. Бер йөк машинасына 3 җиңел машина туры килә. Гаражда ничә йөк машинасы, ничә җиңел машина бар?

186 Кисемтәле модель ясап чиш.

Сөмбел Таңсылудан 3 тапкыр кечерәк. Ә әнисе Таңсылудан 3 тапкыр олырак. Сөмбел белән әнисенә бергә 40 яшь. Сөмбелгә ничә яшь?

187 Өч сыйныфта 69 бала укый. Икенче сыйныфта 22 укучы, беренче һәм икенче сыйныфта барысы 46 укучы. Беренче һәм өченче сыйныфта ничәшәр бала укый?

188 Бер үк санны Гали — 8 гә, Вәли 9 га бүлде. Галинең өлештә дә, калдыкта да 6 чыкты. Вәли нинди сан уйлаган?

189 38 гә ничәне кушсаң, 3 кә бүленә торган сан килеп чыга? Шул саннарны куеп карап чиш. Фәрхәткә — 8, әтисенә 38 яшь. Ничә елдан соң әтисе улыннан 3 тапкыр олырак булыр?

190 Ике участоктан 32 ц кишер уңышы җыйганнар. Беренче кишәрлектәге уңыш икенчесенә караганда 8 ц га азрак булган. Һәр кишәрлектән күпме кишер җыйганнар?

191 Кисемтәле модель ясап чиш.
36 бала төрле түгәрәкләргә йөри. Һәр 4 баланың берсе — бию, һәр 6 баланың берсе — хор, һәр 9 баланың берсе компьютер өйрәнү түгәрәгендә шөгыльләнә. Калганнары чит телләр өйрәнү түгәрәгенә йөри. Һәр түгәрәктә ничәшәр бала?

192 Бөтен һәм өлешләргә бүлеп карап чиш. Бәйрәмгә алынган 1 кызыл төстәге шарга 3 яшел төстәге шар туры килә. Барысы 40 шар булса, шуларның ничәсе кызыл, ничәсе яшел булган?

193 Саннарны баганалап язып, гамәлләрне башкар.

381 + 164 465 − 173 746 − 336

194 Кайсы мисаллар дөрес чишелмәгән? Аларны җавапларын дөресләп күчереп яз.

643 + 38 = 1 023
745 − 162 = 683
615 + 385 = 1 000

195 Кайсы санны 132 гә киметсәң, 293 була?

196 Иң зур бишурынлы һәм иң кечкенә дүртурынлы саннарны яз.

197 Беренче көнне 232 га җир сөрелгән, бу икенче көндәгегә караганда 48 га га кимрәк. Ике көндә ничә гектар җир сөрелгән?

198 Дүртурынлы сан килеп чыксын өчен, нинди өчурынлы санга 1 не кушарга кирәк?

199 Баганалап язып исәплә.

645 + 355 648 − 169 857 − 347

200 Җаваплары дөрес булмаган мисалларны дөресләп күчереп яз.

$758 + 42 = 1\ 178$
$896 - 249 = 657$
$448 + 52 = 500$

201 Кайсы санны 68 гә арттырсаң, 142 була?

202 Иң кечкенә алтыурынлы, иң зур җидеурынлы санны яз.

203 Беренче көнне 369 га җир сөрелгән, бу икенче көндәгегә караганда 59 га га артыграк. Ике көндә ничә гектар җир сөрелгән?

204 Дүртурынлы сан килеп чыксын өчен, нинди бишурынлы саннан 1 не алырга кирәк?

3 КҮБУРЫНЛЫ САННАРНЫ ТАПКЫРЛАУ ҺӘМ БҮЛҮ

205 Исәплә.

4 + 4 + 4 + 4
6 + 6 + 6 + 6 + 6
7 + 7 + 7 + 7 + 7 + 7
3 + 3 + 3 + 3 + 3 + 3 + 3

206 Уңайлы юл белән исәплә.

6 + 4 + 6 + 4 + 6 + 4 + 6 + 4 + 6 + 4
6 + 4 + 4 + 4 + 6 + 6 + 6 + 6 + 4
8 + 8 + 3 + 8 + 3 + 8 + 3 + 3 + 3 + 5+ 5 + 5 + 3

207 Бер капта 6 карандаш. Шундый ук 7 капта ничә карандаш булыр?

208 Сумманы тапкырлау белән алыштырып яз.

57 + 57 + 57
28 + 28 + 28 + 28
84 + 84 + 84 + 84 + 84
0 + 0 + 0 + 0 + 0

209 Мәктәп китапханәсенә 3 кап китап алып кайттылар. Һәр капта 20 шәр китап. Китапханәгә ничә китап алып кайтылган?

210 Тапкырлау гамәлен кушу гамәле белән алыштыр. Җавапны исәплә.

$23 \cdot 5$ $\quad$ $82 \cdot 3$
$46 \cdot 4$ $\quad$ $105 \cdot 2$

a санының *b* санына тапкырчыгышы — һәрберсе *a* га тигез булган *b* кушылучыларның суммасы.

$$a \cdot b = \underbrace{a + a + \ldots + a}_{b}$$

211 Тапкырчыгышны цифрлар белән яз. Нәтиҗә яса.

1 дистә · 10 $\quad$ 3 дистә · 10
1 йөз · 10 $\quad$ 3 йөз · 10
1 мең · 10 $\quad$ 3 мең · 10

212 Исәплә.

$32 \cdot 10 = (30 + 2) \cdot 10$ $\quad$ $568 \cdot 10$
$453 \cdot 10 = (400 + 50 + 3) \cdot 10$ $\quad$ $9\,470 \cdot 10$

213 Һәр санны 10 тапкыр зурайт.

50, 143, 2 005, 80 307, 205 050.

214 x ны тап.

$(x + 142) : 10 = 23$

$(72 + x) : 4 = 30$

215 Исәплә.

$40 \cdot 4 = 4$ дистә $\cdot 4$

$70 \cdot 5 = 7$ дистә $\cdot 5$

$90 \cdot 6 = (9 \cdot 10) \cdot 6 = (9 \cdot 6) \cdot 10$

$80 \cdot 8$

216 Телдән исәплә.

$68 \cdot 4 = (60 + 8) \cdot 4$

$27 \cdot 5$

$36 \cdot 6$

$48 \cdot 8$

$54 \cdot 4$

$77 \cdot 7$

Санны 10 га тапкырлаганда, санның азагына бер нуль өстәлә.
Санның 10 га тапкырчыгышын табу өчен, шул санның азагына бер нуль өстәп язарга кирәк.

217 Ничек исәпләгәнне аңлат.

$43 \cdot 100 = (43 \cdot 10) \cdot 10 = 430 \cdot 10 = 4\,300$

$58 \cdot 100$

$69 \cdot 100$

218 Гамәлләрне башкар.

$643 \cdot 100$ $506 \cdot 100$
$442 \cdot 100$ $330 \cdot 100$
$50 \cdot 100$ $208 \cdot 100$

219 Аңлатмаларның кыйммәтен тап.

$(443 + 657) \cdot 100$ $892 \cdot 100 - 9\,200$
$(1\,155 - 455) \cdot 100$ $11\,700 - 17 \cdot 100$

220 Тигезләмәләрне чиш.

$1\,200 \cdot 4 - x = 800$ $x - 60 \cdot 100 = 70\,000$

221 6 485 санының уң ягына ике нуль өстәп яздылар. Сан ничек үзгәрде?

222 Бер атка бер көнгә 12 кг солы бирәләр. 10 атка бер көнгә күпме солы кирәк? 10 атка 10 көнгә күпме солы кирәк?

Санның 100 гә тапкырчыгышын табу өчен, шул санның азагына ике нуль өстәп язарга кирәк.

223 Ничек исәпләгәнне аңлат. Исәплә.

$28 \cdot 1\,000 = (28 \cdot 100) \cdot 10 = 2\,800 \cdot 10 = 28\,000$
$47 \cdot 1\,000 = (47 \cdot 100) \cdot 10$
$238 \cdot 1\,000 = (238 \cdot 100) \cdot 10$

224 Метрларда яз.

3 км 140 м
2 км
25 км
145 км 300 м

225 Исәплә.

628 · 1 000
68 · 1 000
30 · 1 000
407 · 1 000

226 Аңлатмаларның кыйммәтен тап.

(200 + 4 000) · 1 000
(62 000 – 60 000) · 1 000
(6 870 – 870) · 1 000
45 · 1 000 – 5 000

227 Санны 10 000 гә, 100 000 гә ничек тапкырларга?

228 Исәплә.

(1 000 + 1 000 + 1 000 + 1 000) : (1 000 + 1 000)

Санның 1 000 гә тапкырчыгышын табу өчен, шул санның азагына өч нуль өстәп язарга кирәк.

229 Исәплә.

30 · 40
60 · 50
80 · 70
90 · 30
50 · 40
50 · 20

230 Гамәлләрне башкар.

$200 \cdot 3\,000$ $\quad$ $900 \cdot 30$

$600 \cdot 500$ $\quad$ $500 \cdot 40$

$800 \cdot 700$ $\quad$ $450 \cdot 200$

231 Кибеткә 3 төргәк ефәк китерделәр. Һәр төргәктә 50 шәр метр. Кибеткә ничә метр ефәк китерделәр?

232 Башлангыч сыйныфларда 420 укучы. Югары сыйныфларда укучылар саны башлангыч сыйныфлардан 3 тапкыр күбрәк. Мәктәптә барысы ничә укучы?

233 Тигезләмәләрне чиш.

$x : 50 + 86 = 986$ $\qquad$ $(x - 120) : 6 = 50$

234 Квадратның ягы 60 см. Периметрын тап.

Түгәрәк саннарны тапкырлаганда, тапкырлауның урын алыштыру һәм оештыру үзлекләре кулланыла.

235 Сумманы тапкырчыгыш рәвешендә күрсәт.

$867 + 867 + 867$

$4\,365 + 4\,365 + 4\,365 + 4\,365$

$a + a + a + a + a + a$

236 Аңлатманың кыйммәтен тап.

$342 + 342 + 342 + 58 + 58 + 58$

237 Исәпләгәндә тапкырлауның нинди үзлекләре кулланылган?

$47 \cdot 3 = (40 + 7) \cdot 3 = 40 \cdot 3 + 7 \cdot 3 = 120 + 21 = 141$

$69 \cdot 5 + 31 \cdot 5 = (69 + 31) \cdot 5 = 100 \cdot 5 = 500$

238 Исәплә.

$73 \cdot 6 + 27 \cdot 6$	$86 \cdot 5$	$63 \cdot 8$
$49 \cdot 8 + 51 \cdot 8$	$97 \cdot 7$	$148 \cdot 3$

239 2 м озынлыктагы 89 япма тегү өчен, ничә метр тукыма кирәк?

240 Бер тартмада 8 кг акбур бар. Шундый ук 13 тартмада ничә килограмм акбур бар?

Тапкырлауның кушуга карата тарату үзлеге.

$$a \cdot (b + c) = a \cdot b + a \cdot c$$

241 142, 235, 346, 908, 400 саннарын 7 тапкыр зурайт.

242 Тапкырла.

$1 \cdot 96$ $27 \cdot 10$ $86 \cdot 100$
$78 \cdot 1$ $149 \cdot 100$ $905 \cdot 100$

243 Чагыштыр.

7 м * 70 дм
3 м 6 дм * 3 м 60 см
8 м 2 дм * 810 см
46 м * 1 м 46 дм
4 м 14 см * 41 дм 4 см
62 м 3 дм * 632 дм

244 Гамәлләрне башкар.

$317 + 317 + 317 + 317$
$425 + 425 + 425 + 425 + 425$
$508 + 508 + 508 + 492 + 492 + 492$

245 Тапкырла.

$145 \cdot 8$ $839 \cdot 9$ $234 \cdot 5$
$256 \cdot 7$ $674 \cdot 6$ $345 \cdot 4$

246 Соңгы цифры 0 гә тигез булган бер сан бирелгән. Шул санның нулен сызсаң, икенче сан килеп чыга. Ике санның суммасы 572 гә тигез. Саннарны тап.

247 Тапкырлауның ничек башкарылганын аңлат.

$374 \cdot 68 = 374 \cdot (60 + 8) = 374 \cdot 60 + 374 \cdot 8 = 25\,432$
$2\,183 \cdot 74 = 2\,183 \cdot (70 + 4) = 152\,810 + 8\,732 = 161\,542$

248 Мисалларның чишелешен баганалап язганнар. Дөреслеген тикшер.

$$\begin{array}{r} 374 \\ \times \quad 60 \\ \hline 22440 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 374 \\ \times \quad 8 \\ \hline 2992 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 2992 \\ + \; 22440 \\ \hline 25432 \end{array}$$

$$\begin{array}{r} 2183 \\ \times \quad 70 \\ \hline 152810 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 2183 \\ \times \quad 4 \\ \hline 8732 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 8732 \\ + \; 152810 \\ \hline 161542 \end{array}$$

249 Язылышларны берләштергәннәр. Дөреслеген тикшер.

$$\begin{array}{r} 374 \\ \times \quad 68 \\ \hline 2992 \\ + \; 22440 \\ \hline 25432 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 2183 \\ \times \quad 74 \\ \hline 8732 \\ + \; 152810 \\ \hline 161542 \end{array}$$

250 Язылыш дөресме? Ни өчен?

$$\begin{array}{r} 374 \\ \times \quad 68 \\ \hline 2992 \\ + \; 22440 \\ \hline 25432 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 2183 \\ \times \quad 74 \\ \hline 8732 \\ + \; 152810 \\ \hline 161542 \end{array}$$

251 Гамәлләрне башкар.

$342 \cdot 41 + 5978$
$406 \cdot 55 - 2330$

252 * урынына төшереп калдырылган цифрларны куй.

```
 x 217        x 3*2
     **          32
 +**85        + *02
  *34          ***
  ****         ****
```

253 Тапкырчыгыш дөрес табылганмы?

$1\,234 \cdot 563 = 1\,234 \cdot (500 + 60 + 3) = 1\,234 \cdot 500 +$
$+ 1\,234 \cdot 60 + 1\,234 \cdot 3 = 617\,000 + 74\,040 + 3\,702 =$
$= 694\,742$
$406 \cdot 353 = 406 \cdot (300 + 50 + 3) = 121\,800 +$
$+ 20\,300 + 1\,218 = 143\,318$

254 Дөрес язылганмы? Аңлат.

```
  x 1234        x 406
     563          353
    3702         1218
 + 7404       + 2030
  6170         1218
  694742       143318
```

255 Тапкырла.

$257 \cdot 642$ $308 \cdot 492$
$158 \cdot 395$ $706 \cdot 541$

256 Гамәлләрне башкар.

$342 \cdot 412 + 9\,096$ $802 \cdot 555 - 45\,110$

257 Аңлатмаларның кыйммәтен тап.

$408 \cdot (4\,808 - 4\,709) + 9\,608$
$338\,017 - 503 \cdot (415 + 257)$

258 1 га дан 158 ц бәрәңге уңышы җыйганнар. 255 га дан ничә центнер уңыш җыйганнар?

259 Телдән исәплә.

$75 \cdot 2$ $75 \cdot 4$ $75 \cdot 8$ $75 \cdot 10$
$68 \cdot 2$ $68 \cdot 4$ $68 \cdot 8$ $68 \cdot 10$

260 Тапкырчыгычны тап.

$160 \cdot 3$ $403 \cdot 3$ $200 \cdot 3$
$130 \cdot 4$ $508 \cdot 6$ $700 \cdot 5$

261 $a \cdot (b + c)$ аңлатмасының кыйммәтен исәплә.
$a = 23$, $b = 1\,412$, $c = 348$.

262 Тапкырлау гамәлен башкар.

878 · 14   3 131 · 74   4 341 · 65
1 189 · 55   78 · 546   89 · 1 345

263 Исәплә.

200 · 6   5 000 · 160   2 400 · 130
300 · 50   1 500 · 330   2 960 · 400

264 Тапкырла.

405 · 604   7 007 · 808   2 004 · 8 008
62 005 · 42   406 · 300   4 460 · 505

265 Тигезләмә төзеп чиш. Санлы турыда күрсәт. 48 конфетны 6 балага тигез итеп бүлгәннәр. Һәр балага ничә конфет тигән?

266 Бүленүче һәм бүлүчене әйт.

64 : 8   54 : 6 $\frac{0}{5}$ $\frac{32}{4}$ 72 : 9 $\frac{36 : 9}{4}$

267 x ны тап.

$9 \cdot x = 81$ $4x + 5 = 21$ $a \cdot x = в$
$x \cdot 7 = 35$ $16 + 8x = 80$ $8 \cdot x - 23 = 41$

268 Ничек исәпләгәнеңне аңлат. Кайсы компонентлар билгесез?

$x : 9 = 7$ $48 : 6 = x$ $18 : x = 3$

269 Кайсы мисалларны эшләп булмый?

15 : 5	30 : 10	30 : 6
15 : 0	30 : 0	30 : 1

270 Бүлүче белән өлеш арасында нинди бәйләнеш бар?

36 : 1	36 : 6	36 : 18
36 : 4	36 : 9	36 : 36

$$a : b = c$$

a — бүленүче, b — бүлүче, c — өлеш.

271 Үрнәк буенча гамәлләрне башкар.

$459 \cdot 10 = 4\,590$
$x \cdot 10 = 4\,590$
$x = 4\,590 : 10$
$x = 459$

$608 \cdot 10 = 6\,080$
$x \cdot 10 = 6\,080$

$43 \cdot 10 = 4\,300$
$x \cdot 10 = 4\,300$

272 Саннарны 10 тапкыр зурайт.

20, 406, 880, 74, 8 560.

273 Саннарны 10 тапкыр кечерәйт.
300, 5 060, 640, 35 600.

274 Җавапны цифрлар белән яз.

7 дистә : 10 5 йөз : 1 дистә
27 дистә : 10 2 мең : 1 дистә

275 Исәплә.

$(3 \cdot x) : 10 = 30$ $(5 \cdot x) : 10 = 500$

276 0, 1, 2, 3 цифрларын кулланып, барлык дүртурынлы саннарны яз. Цифрлар кабатланмасын. Ничә сан яздың?

Түгәрәк санны 10 га бүлү өчен, аның уң ягыннан бер нулен сызарга кирәк.

277 Тапкырчыгышны исәплә.

$304 \cdot 100$ $3\,400 \cdot 100$
$8\,006 \cdot 100$ $500 \cdot 100$

278 Гамәлләрне үрнәк буенча башкар.

$648 \cdot 100 = 64800$
$64800 : 648 = 100$
$64800 : 100 = 648$

$409 \cdot 100 = 40900$
$380 \cdot 100 = 38000$

279 Аңлатманың кыйммәтен тап.

6 400 : 100 + 36
809 000 : 100 + 1 910
708 · 100 : 10
65 · 10 + 35 000 : 100

280 Чагыштыр.

80 100 * 81 000
61 408 * 61 804
43 060 * 43 006
5 800 * 50 800

281 Исәплә.

308 000 : 100 : 10
(48 600 – 600) : 10 : 100
800 000 : 1 000
8 500 – 500 000 : 1 000

282 Өч яки күбрәк нульгә беткән саннарны 1 000 гә ничек бүләргә? Мисаллар китер.

Ике яки күбрәк нульгә беткән саннарны 100 гә бүлгәндә, санның уң ягыннан ике нулен сызарга кирәк.

283 Өлештә ничә цифр булыр?

2 йөз 6 дистә 7 бер : 3
2 мең 6 дистә 7 бер : 3
20 мең 6 дистә 7 бер : 3
26 мең 7 йөз : 3

284 Икеурынлы, өчурынлы, бишурынлы санны берурынлы санга тапкырлаганда, ничә урынлы сан чыга? Мисаллар китер.

285 Икеурынлы, өчурынлы, тугызурынлы санны берурынлы санга бүлгәндә, өлештә ничә урынлы сан булыр? Мисаллар белән дәлиллә.

286 Бүлүне ничек башкарганны аңлат.

$$\begin{array}{r|l} 267 & 3 \\ \hline -24 & 89 \\ 27 & \\ -27 & \\ 0 & \end{array} \qquad \begin{array}{r|l} 2067 & 3 \\ \hline -18 & 689 \\ 26 & \\ -24 & \\ 27 & \\ -27 & \\ 0 & \end{array} \qquad \begin{array}{r|l} 26700 & 3 \\ \hline -24 & 8900 \\ 27 & \\ -27 & \\ 0 & \end{array}$$

287 Өлештә ничә цифр буласын нокталар белән билгеләгәннән соң, бүлүне башкар.

$$\begin{array}{r|l} 1\,016 & 8 \\ \hline & \end{array} \qquad \begin{array}{r|l} 7\,869 & 3 \\ \hline & \end{array} \qquad \begin{array}{r|l} 4\,290 & 6 \\ \hline & \end{array}$$

288 Бүлүне башкар.

868 : 7   1 880 : 8   2 304 : 6

289 Телдән исәплә.

42 : 2 = 4 дистә : 2 + 2 бер. : 2 =
86 : 2 =
140 : 2 =

290 Исәплә.

66 : 3 24 : 4 45 : 3
93 : 3 88 : 4 450 : 9
210 : 3 96 : 4 450 : 5

291 Өлештә ничә цифр буласын нокталар белән билгелә.

48 : 2 63 : 3 49 : 7
22 : 2 96 : 3 70 : 7
240 : 2 366 : 3 140 : 7
4 862 : 2 3 996 : 3 2 142 : 7

292 Зурлыкларны 7 тапкыр кечерәйт.

14 км 210 м 7 т 210 кг
350 кг 140 г 6 сәг 4 мин

293 Бүлүне эшләп бетер.

−67 158 | 6
6 | 1....

−123 458 | 7
7 | 1....

294 Өлештә ничә цифр буласын нокталар белән билгелә.

420 : 70 8 100 : 90 32 000 : 800
4 000 : 50 540 : 60 4 200 : 60

295 Бүленүчене һәм бүлүчене бүлүченең югары разрядына кадәр түгәрәклә. Өлешне тап.

76 : 19 6 120 : 18 3 808 : 34
391 : 17 513 : 27 14 766 : 46

296 Гамәлләрне башкар.

145 · 32 321 · 23 456 · 32
4 640 : 32 7 383 : 23 14 592 : 32

297 Бүлүне башкар.

840 : 40 9 600 : 30 228 000 : 20

298 Өлешне тап.

1 185 : 15 1 785 : 15 3 045 : 15 9 000 : 15

299 Таблицадагы буш урыннарны тутыр.

Бүленүче	Бүлүче	Өлеш
5 424	12	
	231	51
3 432		143

300 2 742 китап төпләргә кирәк. Һәр көнне 457 китап төпләсәләр, китапларны ничә көндә төпләп бетерерләр?

301 Өлешне тап.

900 : 300   44 400 : 444   1 250 : 250
450 : 150   5 600 : 700   3 500 : 500

302 Бүлүнең дөреслеген тапкырлау ярдәмендә тикшер.

43 815 : 127 = 345
7 474 : 202 = 37
9 418 : 277 = 34

303 Бүлүченең югары разрядына кадәр бүленүчене һәм бүлүчене түгәрәклә. Өлешне тап.

3 270 : 654   8 904 : 742   4 784 : 218

304 Гамәлләрне башкар.

(3 096 : 258 + 188) · 5
(126 − 8 424 : 324) : 20

305 Аңлатманың кыйммәтен исәплә.

(13 959 : 423 + 21 507 : 321) · 64
(23 790 : 305 − 10 304 : 368) · 22

306 67, 243, 1 632, 885 саннарын 10 га бүлгәндә, калдыкны тап.

307 Саннарны 100 гә бүлгәндә, калдыкны тап.

241, 3 467, 12 877, 907.

308 529 ны 16 га бүлеп, шундый нәтиҗә язганнар:
$529 = 16 \cdot 32 + 17$. Дөресме?

309 Калдыклы бүлүне башкаруның җиңел ысулын тап.

$1 \cdot 2 \cdot 3 \cdot 4 + 1$ не 4 кә бүл.
$1 \cdot 2 \cdot 3 \cdot 4 \cdot 5 + 1$ не 5 кә бүл.
$1 \cdot 2 \cdot 3 \cdot 4 \cdot 5 \cdot 6 + 1$ не 6 га бүл.

310 Таблицаны тутыр.

Бүленүче	Бүлүче	Тулы булмаган өлеш	Калдык
5 455	44		
10 490		456	
	23	148	6

311 Аңлатмаларның кыйммәтен тап.

6 000 : (38 855 : 95 – (5 642 – 5 533))
443 443 : (645 · 23 – 13 834)

312 Теләсә нинди санга 1 не куш. Нинди нәтиҗә ясап була?

313 Теләсә нинди саннан 1 не ал. Җавапта нинди сан була?

314 Теләсә нинди санны 1 гә тапкырла. 1 не теләсә нинди санга тапкырла. Нәтиҗә яса.

315 Теләсә нинди санны 1 гә бүл. Тапкырлау гамәлен кулланып тикшер.

316 Гамәлләрне башкар.

$423 \cdot 1 + 377 : 1$

$(869 - 868) \cdot 39 + 61$

$6\,347 : 6\,347 + 999$

$548 : (1\,000 - 999) + 52$

317 Рәттән ун тапкыр 1 цифрын яз. Җавапта 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10 саннары булырлык итеп, алар арасына гамәл тамгалары куй. Төрле ысуллар белән эшлә.

318 Исәплә.

$9\,999 + 9\,999 + 9\,999 + 4$

$997 + 997 + 997 + 10$

$99 + 99 + 99 + 3$

$98 + 97 + 99 + 6$

319 Тапкырлауның тарату үзлеген куллан.

$62 \cdot 28 + 38 \cdot 28$

$315 \cdot 93 - 215 \cdot 93$

$854 \cdot 95 + 146 \cdot 95$

$736 \cdot 80 - 536 \cdot 80$

320 Гамәлләрне башкар. Ялгышма!

0 : 142   135 : 1   6 458 · 1   23 : 0

321 Тапкырлауның оештыру үзлеген кулланып исәплә.

5 · 3 · 2 · 4   66 · 25 · 4
8 · 5 · 4 · 3   21 · 5 · 3 · 2
11 · 5 · 3 · 2   34 · 2 · 5 · 2

322 Җиңел юл белән исәплә.

(643 · 25) · 4   (428 · 4) · 25

323 Чагыштыр.

(147 + 239) + (239 − 147) * 2 · 147
(666 + 439) + (666 − 439) * 2 · 666
(548 + 291) + (548 − 291) * 2 · 548

324 Язып бетер.

345 · 4 = (300 + 40 + 5) · 4 = 300 · 4 + …
2 678 · 3 = (2 000 + 600 + 70 + 8) · 3 = 2 000 · 3 + …

325 Баганалап язып тапкырла.

423 · 5 678 · 3   1 234 · 6

326 Тапкырчыгышта ничә цифр булыр?

1 231 · 5 647 · 4 14 643 · 4

327 Тапкырлау гамәлен аңлатып эшлә.

456 · 37 182 · 45 374 · 6

328 Тапкырчыгышта ничә цифр булыр?

126 · 17 4 567 · 28 406 · 23

329 Бер мәктәпкә — 23 кап, икенче мәктәпкә 32 кап китап алганнар. Бер капта 16 китап булса, һәр мәктәп ничә китап алган?



330 Исәплә.

148 · (100 – 1) 34 · 99 4 444 · 9 999
15 · (1 000 – 1) 156 · 999 6 666 · 5

331 Иң зур өчурынлы санны үз-үзенә тапкырла. Тапкырчыгышта ничә урынлы сан килеп чыкты?

332 Тапкырчыгышта ничә урынлы сан булыр?

Мисаллар ярдәмендә җавабыңның дөреслеген тикшер.

333 Нокталар урынына цифрлар яз.



334 Һәр рәткә 25 әр төп агач утыртканнар. Алмагачлар — 12 рәт, карлыганнар 17 рәт утыртылса, барысы ничә төп агач утыртканнар?

335 Өлештә ничә цифр булыр?

63 : 9	2 652 : 427
261 : 87	9 872 : 1 234
315 : 45	149 522 : 21 346

336 Бүленүчене бүлүченең югары разрядына кадәр түгәрәклә.

84 : 21	1 926 : 321	7 536 : 1 256
126 : 18	3 206 : 458	18 712 : 4 678

337 Өлештә нинди сан буласын чамалап әйт.

87 : 21	1 924 : 321	7 530 : 1 256
128 : 18	3 204 : 458	18 716 : 4 678

338 Бүлүне башкар.

84 : 21	1 926 : 321	7 536 : 1 256
126 : 18	3 206 : 458	18 712 : 4 678

339 Гамәлләрне башкар.

$(240 + 150) : 3$	$450 - 220 \cdot 2 + 140$
$(630 - 230) \cdot 10$	$600 - 120 \cdot 3 + 160$

340 Мәктәпкә *A* өстәл һәм урындыклар алдылар. Урындыклар саны өстәлләргә караганда *C* га күбрәк. Мәктәпкә күпме өстәл һәм урындыклар алганнар?

341 Өлештә ничә дистә булыр?

400 : 2	810 : 9	60 : 2
600 : 3	360 : 4	50 : 5

342 Саннарда якынча ничә йөз бар?

192, 275, 315, 444, 536, 665.

343 Өлештә нинди сан буласын чамалап әйт һәм бүлүне башкар.

180 : 36　　　1 164 : 194
185 : 37　　　2 916 : 486

344 Бүлүне башкар.

1 729 : 247　　　14 592 : 1 824
2 274 : 379　　　6 429 : 2 143

345 Гамәлне башкар.

(6 932 : 1 733 + 96) : 100

346 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



347

Өлештә ничә цифр булуы нәрсәгә бәйле?

6 : 2 60 : 6 2 000 : 2
18 : 3 400 : 4 2 000 : 4

348

Өлештә ничә цифр булырга мөмкин?

349

Өлештә ничә цифр?

40 : 20 6 000 : 60
240 : 60 6 000 : 30



350

Бүлүне башкар.

300 : 15 300 : 30
6 000 : 15 3 000 : 60

351

Гамәлне башкар.

(450 : 3 + 150) : 3 −100

5 К 5/270

352 Чишелеше буенча мәсьәлә төзе.

$100 - 19 \cdot 2$

353 Өлештә ничә урынлы сан булыр?

900 : 300	1 800 : 300	18 000 : 600
450 : 150	4 500 : 150	45 000 : 150



354 Бүлүне башкар.

800 : 400	8 000 : 200	60 000 : 200
500 : 250	5 000 : 250	500 000 : 250

355 Башта өлештә нинди сан буласын чамала, аннары өлешне тап.

861 : 123	(9 йөз : 1 йөз)
2 415 : 345	(24 йөз : 3 йөз)
4 536 : 567	(45 йөз : 6 йөз)
6 102 : 678	(61 йөз : 7 йөз)

356 Бүлүне башкар.

1 284 : 321	5 256 : 657
1 305 : 435	6 251 : 893

357 Гамәлләрне башкар.

5 100 − (2 572 : 643 + 4 996)
(5 100 − 2 528) : 643 + 96

358 Билгесез саннан 54 не алып, килеп чыккан аерманы 16 га бүлгәч, 6 килеп чыга. Билгесез санны тап.

359 Дүртурынлы санга бүлгәндә, өлештә ничә урынлы сан чыга?

6 000 : 3 000	5 000 : 2 500	600 000 : 6 000
60 000 : 2 000	70 000 : 3 500	70 000 : 3 500

360 Өлештә ничә цифр булыр?



361 Өлешне исәплә.

6 170 : 1 234	51 102 : 5 678
14 070 : 2 345	59 024 : 8 432

362 Бүлүне башкар.

25 926 : 4 321 35 024 : 8 756
38 024 : 5 432 18 784 : 2 348

363 Мисалларны чиш.

(94 + 19 284 : 3 214) : 5
(12 428 + 13 284) : 3 214 + 198

364 Кибеттә 480 м ситсы бар иде. Тагын 50 шәр метрлы *А* төргәк ситсы китерделәр. Барлыгы ничә метр ситсы булды?

365 Баганалап язып тапкырла.

167 · 324 589 · 347

366 Өлештә ничә цифр булыр?

54 108 : 324 204 383 : 589

367 Тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен чагыштыр.

```
 x  324         _54108 | 324
    167          32400 |-----
   -----         ----- | 167
   2268         _21708
 + 1944          19440
   324           -----
 -------         _2268
   54108          2268
                  ----
                     0
```

368 Бүлүне башкар.

204 383 : 589 36 608 : 256

369 Гамәлләрне башкар.

4 625 : 37 10 764 : 468
125 · 37 468 · 256

370 Берничә малай 87 балык тоткан. 3 малай — 9 ар балык, ә калганнары 10 арны тоткан. Барысы ничә малай балык тоткан?

371 Телдән исәплә.

120 + 80 − 240 : 6 · 5
80 · 2 + 40 − 400 : 5 − 120
300 − 25 · 2 · 4 − 80
120 · 2 − 120 : 6

372 Бүлүне башкар. Бүлә башлаганчы өлештә ничә урынлы сан булачагын ачыкла.

108 834 : 51 2 407 296 : 200 608

373 Тапкырлау һәм бүлүне эшлә.

147 · 213 34 · 184 47 · 53
31 311 : 147 6 256 : 34 2 491 : 47
31 311 : 213 6 256 : 184 2 491 : 53

374 Бүлүнең дөреслеген тапкырлау ярдәмендә тикшер.

$2\,457 : 91 = 27$

$10\,959 : 281 = 39$

$58\,548 : 82 = 714$

$2\,448 : 48 = 52$

375 Гамәлләрне башкар.

$(28\,447 - 817\,760 : 269) + 4\,593$

$(5\,030 + 960\,520 : 236) : 50$

376 Уйлаган санны 17 тапкыр кечерәйтеп, нәтиҗәгә 80 не кушсаң, 120 килеп чыга. Уйлаган санны тап.

377 Иң уңайлы юл белән исәплә.

$998 \cdot 647 + 2 \cdot 647$

$89 \cdot 142 + 10 \cdot 142 + 142$

$863 \cdot 5 \cdot 20$

$189 + 708 + 92 + 11$

378 Кайсы зуррак: a мы, b мы?

$a = b + 27$

$a : b = 4$

$a \cdot 48 = b$

$a : 3 = b$

$b + 17 = a$

$a - 26 = b$

379 x ны тап.

$x + x + x = 643 \cdot 3$

$(x + 48) \cdot 7 = 12 \cdot 7 + 48 \cdot 7$

380 Аңлатмаларны укы һәм гамәлләрне башкару тәртибен күрсәт.

$A \cdot B + C$ $\quad$ $(A \cdot B + C) \cdot D$

$A : B - C \cdot D$ $\quad$ $A : B + (C - D)$

381 Тигезләмәләрне чиш.

$(36 - 240 : x) \cdot 6 = 96$

$8 + (y - 28) : 3 = 38$

382 Чишелеше буенча мәсьәлә төзе.

$x = 36 + (36 + 7) + (36 - 3)$

4 ТИГЕЗЛӘМӘЛӘР

383 Мәсьәләләрне тигезләмә төзеп чиш. Билгесез санга 38 не кушсаң, 100 була. Билгесез санны тап.

384 Кибеткә 14 тартма лимон китерделәр. Кибеткә 560 лимон китерелгән булса, һәр тартмада ничә лимон?

385 5 саны $3x + 5 = 13$ тигезләмәсенең чишелеше була аламы? Аңлат.

386 Тигезләмәдәге билгесезне төрле хәрефләр белән күрсәткәннәр. Тигезләмәләрне чиш.

$a + 142 = 300$ $\quad$ $c - 432 = 665$

$1\,246 - b = 347$ $\quad$ $768 + x = 1\,000$

387 Ике санның тапкырчыгышы 3 510. Беренче тапкырлаучы — 45. Икенче тапкырлаучыны тап.

388 643 + 357 = 1000 тигезлеген кулланып, төрле тигезләмәләр яз.

Билгесез санны эченә алган тигезлек **тигезләмә** дип атала.

389 Билгесезнең тигезләмәне санлы тигезлеккә әйләндергән кыйммәтен тап.

$x + 142 = 288$ $\quad$ $x \cdot 5 = 100$

$3\,052 - x = 582$ $\quad$ $810 : x = 90$

390 Билгесез санга 28 не кушсаң, 99 була. Билгесез санны x дип билгеләп, тигезләмәләр төзе.

391 x ны 4 кә тапкырласаң, 284 була. x ны тап.

392 99 дан нинди санны алсаң, 28 була. Тигезләмә төзеп чиш.

393 284 не A га бүлсәң, 4 була. A ны исәплә.

394 Тигезләмәләрне чиш.

$257 + x = 502$ $\quad$ $4\,053 - x = 783$

$3\,152 - x = 997$ $\quad$ $x - 6\,547 = 1\,243$

Билгесезнең тигезләмәне санлы тигезлеккә әйләндерә торган кыйммәтен **тигезләмәнең тамыры** дип атыйлар.

395 x ны телдән исәплә.

$(x + 13) + 19 = 49$ $(x + 14) - 8 = 68$
$(17 + x) + 15 = 65$ $(x - 44) + 12 = 48$

396 Тигезләмәләрнең тамырын тап.

$(x + 242) + 47 = 478$ $(x + 1\,426) - 91 = 2\,369$
$(263 + a) + 85 = 693$ $(x - 448) + 121 = 4\,000$

397 Мәсьәләләрне тигезләмә төзеп чиш.
Тукталышта берничә машина бар иде. 12 машина кузгалып киткәч, яңадан 48 машина килеп туктады. Анда 79 машина булды. Тукталышта ничә машина булган?

398 Тигезләмәләрне чиш.

$(x + 187) + 796 = 467 + (187 + 796)$
$(339 + x) + 879 = 339 + (53 + 879)$

399 Хәрефнең кыйммәте нинди булганда, тигезлек дөрес була?

$58 + x = 58$ $81 - x = 81$ $67 - x = 0$
$x + 23 = 23$ $x - 74 = 0$ $x + 0 = 0$

400 Гамәлләрне башкармыйча гына чагыштыр.

648 + 432 * 32 + 550
1 648 − 342 * 1 558 − 342
1 468 − 1368 * 0

401 x ны телдән исәплә.

$45 + 65 + x = 200$ $(140 - x) + 42 = 382$
$x + 14 + 43 = 87$ $645 - (x + 68) = 345$

402 Тигезләмә төзеп чиш.
Автобуста берничә пассажир бар иде. Тукталышта 11 кеше төшеп, 8 кеше кергәч, 48 пассажир булды. Башта автобуста ничә пассажир булган?

403 Тигезләмәләрне чиш.

$925 + 45 + x = 2\,200$
$x + 146 + 438 = 1\,640$

404 Билгесез санга 61 420 не кушып, 12 770 не алсаң, 1 000 000 була. Билгесез санны тап.

405 Тигезләмәнең тамырын тап.

$1\,998 - (x - 412) = 656$

406 Түбәндәге тигезләмә белән чишәрлек итеп, мәсьәлә төзе.

$(x + 146) - 36 = 440$

407 x ны табуны гамәл компонентлары аша аңлат.

$x + 14 = 70$ $\quad$ $x - 48 = 90$

$29 + x = 89$ $\quad$ $100 - x = 35$

408 x ның кыйммәте нинди булганда, $312 + 88 - x$ аңлатмасының кыйммәте 215 кә тигез була?

409 1 456, 764, 968, 636 саннары арасында $(x + 242) - 642 = 236$ тигезләмәсенең тамыры бармы?

410 Әминә бер сан уйлады. Шул саннан 132 не алып, килеп чыккан санга 467 не кушкач, 612 булды. Әминә уйлаган санны тап.

411 Исәплә.

$259\,877 + 53\,123 - 13\,000$

$748\,744 - 352\,958 + 103\,214$

412 Әгәр $x = 84$ булса, $(345 + x) - 29 < 405 - 6$ тигезсезлегe дөресме?

413 Тигезләмәләрне чиш. Гамәл компонентлары ярдәмендә аңлат.

$5 \cdot x = 45$ $\quad$ $6 \cdot x = 6$

$x \cdot 8 = 72$ $\quad$ $x \cdot 345 = 345$

414 Тигезләмәләрне чиш.

$81 \cdot x = 81$ $\quad$ $24 \cdot x = 240$

$x \cdot 39 = 39$ $\quad$ $x \cdot 12 = 360$

415 x ны тап.

$4 \cdot x + 642 = 786$ $\quad$ $4 \cdot (x - 131) = 36$

$417 + 6 \cdot x = 465$ $\quad$ $(x + 23) \cdot 5 = 300$

416 A ның кыйммәте нинди булганда, $48 \cdot A - 36$ аңлатмасының кыйммәте 300 гә тигез?

417 Тигезләмәләрнең тамырын тап.

$(8 \cdot x) \cdot 125 = 1\,000$ $\quad$ $20 \cdot 30 \cdot x = 12\,000$

$25 \cdot (x \cdot 3) = 750$ $\quad$ $x \cdot 13 \cdot 6 = 3\,900$

418 Чишелеше буенча мәсьәлә төзе.

$36 \cdot 35 - 260$

Билгесез тапкырлаучыны табу өчен, тапкырчыгышны билгеле тапкырлаучыга бүләргә кирәк.

419 Тигезләмәләрне чишүне гамәл компонентлары ярдәмендә аңлат.

$42 : x = 6$ $63 : x = 1$
$x : 7 = 9$ $x : 573 = 1$

420 Тигезләмәләрне чиш.

$98 : x = 1$ $480 : x = 48$
$x : 1 = 647$ $x : 54 = 10$

421 x ны тап.

$x : 7 - 19 = 30$ $63 : x + 123 = 130$
$479 - x : 9 = 470$ $1\,342 + 124 : x = 1\,373$

422 Тигезләмә төзеп чиш.
x белән 347 нең суммасы 31 нең 17 гә тапкырчыгышына тигез.

423 Тигезләмәләрнең тамырын тап.

$7\,800 : x + 200 = 400$ $1\,000 - 10 : x = 995$
$986 - x : 25 = 982$ $(689 - x : 1) - 87 = 602$

424 Чишелеше буенча мәсьәлә төзе.

940 : (710 : 142)

Билгесез бүленүчене табу өчен, өлешне бүлүчегә тапкырларга кирәк.
Билгесез бүлүчене табу өчен, бүленүчене өлешкә бүләргә кирәк.

425 Тигезләмә төзеп чиш һәм дөреслеген тикшер. 100 дән билгесез санны алып, аерманы 9 га бүлсәң, 8 була. Билгесез санны тап.

426 150 ветеранны театрга алып бару өчен, берничә автобус алдылар. Һәр автобуска ветераннарны кеше санын тигез итеп утырттылар. Тагын ике озатучы утырды. Әгәр һәрберсендә 37 шәр пассажир булса, барысы ничә автобус алганнар?

427 Тигезләмә төзеп чиш һәм дөреслеген тикшер. x белән 503 саны суммасының 42 гә тапкырчыгышы 25 200 гә тигез. x ны тап.

428 158 саныннан билгесез санны алып, аерманы 4 кә бүлсәң, 25 була. Билгесез санны тап.

429 Кибеттә 378 дәфтәр бар иде. Аның берничәсен саткач, калган дәфтәрләрне 26 балага 4 әр итеп бүлеп бирделәр. Ничә дәфтәр сатылган?

430 Түбәндәге тигезләмә ярдәмендә чишелә торган мәсьәлә төзе.

$(246 - x) : 26 = 6$

431 Исәплә.

$x : 5 = 13$ $\quad$ $45 : 5 = x$

$35 : x = 7$ $\quad$ $x : 28 = 5$

432 x ны исәпләмә. Аны табу гамәлен генә яз. Ялгышма!

$x \cdot 13 = 78$ $\quad$ $42 : x = 84$

$x : 24 = 48$ $\quad$ $36 \cdot x = 6$

433 Тигезләмәләрнең тамырын тап.

$x - 6\,459 = 0$ $\quad$ $x : 200 = 8$

$640 : x = 80$ $\quad$ $x \cdot 40 = 2\,800$

434 Илдар Рөстәмгә 3 тигезләмә чишәргә биргән. Рөстәм 3 тигезләмәнең чишелешен дә $x = 168 : 21$ дип язган. Илдар нинди тигезләмәләр биргән?

435 Чишелеше $x = 1\,432 - 345$ булган өч тигезләмә төзе.

436 Исәпләүдәге хаталарны тап. Исәпләүне дөрес итеп башкар.

$$\begin{array}{r} \times\ 479 \\ 305 \\ \hline 2395 \\ +\ 1437 \\ \hline 16765 \end{array} \qquad \begin{array}{r} \times\ 1280 \\ 25 \\ \hline 640 \\ +\ 256 \\ \hline 3200 \end{array} \qquad \begin{array}{r} \times\ 810 \\ 270 \\ \hline 567 \\ +\ 162 \\ \hline 2187 \end{array}$$

437 Билгесез сан һәм 240 ның суммасын 60 ка бүлгәч, 6 була. Билгесез санны тап.

438 480 не билгесез санга бүлеп, өлештән 26 ны алгач, 54 була. Билгесез санны тап.

439 Иң кечкенә бишурынлы саннан ничәне алсаң, 999 була?

440 499 һәм 1 саннарының суммасын ничәгә бүлсәң, 100 була?

441 Тигезләмәләрнең тамырын тап.

$(x + 142) : 71 = 8$ $\qquad$ $568 : 71 + x = 71$

$(426 + x) : 8 = 71$ $\qquad$ $568 : 8 + x : 8 = 71$

442 Исәпләүдәге хаталарны тап. Дөрес итеп исәплә.

$$
\begin{array}{r|l}
-80320 & 160 \\ \cline{2-2}
\underline{800} & 52 \\
-320 & \\
\underline{320} & \\
0 &
\end{array}
\qquad\qquad
\begin{array}{r|l}
-15600 & 60 \\ \cline{2-2}
\underline{120} & 260 \\
-360 & \\
\underline{360} & \\
0 &
\end{array}
$$

5 ХӘРӘКӘТКӘ МӘСЬӘЛӘЛӘР

Вакыт.

443 Бер тәүлектә ничә минут? Бер елда ничә сәгать?

444 Вәли спорт түгәрәгендә — 1 сәг 10 мин, ә апасы Галия китапханәдә 70 мин булган. Кемнең вакыты күбрәк үткән?

445 Казаннан Яр Чаллыга баручы автобус 9 сәг 45 мин та кузгалып киткән һәм 13 сәг 20 мин та барып җиткән. Юлда ул 20 мин туктап торган. Автобус ничә минут барган? Ничә секунд туктап торган?

446 Рөстәм мәктәпкә 8 сәг 30 мин та килеп, 12 сәг 20 мин та кайтып китте. Ул мәктәптә күпме булган?

447 Җавапларны үсә бару тәртибендә урнаштырсаң, вакыт үлчәүнең бер берәмлеге исеңә төшәр.

26	8	80	81	54
+	·	−	:	:
16	9	8	9	6
:	−	:	·	+
7	8	9	7	18
·	+	+	+	:
9	47	105	53	3
+	−	−	−	+
60	12	13	3	41
Р	А	С	Ы	Г

448 Елның ничә аенда 30 көн бар?

Юл.

449 Меңнәр һәм берәмлекләр белән күрсәт.

3 742 = ☐ мең ☐ бер   2 005 = ☐ мең ☐ бер
4 023 = ☐ мең ☐ бер   37 300 = ☐ мең ☐ бер

450 Километрлар һәм метрлар белән күрсәт.

3 635 м = ☐ км ☐ м   3 007 м = ☐ км ☐ м
4 013 м = ☐ км ☐ м   43 400 м = ☐ км ☐ м

451 *B* ноктасы уртак булган ике кисемтә белән сыз.
AB = 4 см 3 мм, *BC* = 3 см 8 мм. *AC* кисемтәсен үлчә. Ике очракны кара (*A*, *B*, *C* нокталары бер турыда ята һәм бер турыда ятмый).

452 Казан — Актаныш юлы Яр Чаллы аша үтә. Казаннан Актанышка — 381 км, Казаннан Яр Чаллыга — 227 км. Яр Чаллы белән Актаныш арасы ничә километр?

453 Гамәлләрне башкар.

8 км − 5 км 360 м
9 дм 3 см 2 мм − 5 дм 64 мм
73 м 4 дм 6 см − 52 м 32 см

454 Мәхмүткә әтисе: «Өстәлдәге иң зур әйберне алып бир әле» — дигән. Өстәлдә карандаш, дәфтәр, китап, кайчы һәм берничә тартма булган. Мәхмүт әйберләрнең кайсына үрелергә белмичә аптырап калган. Ни өчен?



Тизлек.

455 Ринат чаңгыда 100 м араны — 25 с та, ә Марат 60 м араны 20 с та үткән. Кем чаңгыда яхшырак шуган?

456 1) Илшат 12 км юлны 3 сәг тә үткән. 1 сәг тә үтелгән юлны санлы турыда күрсәт.

2) Хәмит шул ук араны 2 сәг тә үткән. Санлы турыда чагыштырып җавап бир: кемнең тизлеге зуррак? Нәрсә ул тизлек?

457 Тизлекне тап.

	Үтелгән юл	Вакыт	Тизлек
Космик кораб	56 км	8 с	
Самолёт	1 600 км	2 сәг	
Поезд	240 км	3 сәг	
Ташбака	6 м	2 мин	
Елгадагы сал	15 км	3 сәг	
Җир шары үз орбитасы буенча	180 км	6 с	

458 «Волга» машинасы 3 сәг тә — 330 км, «Жигули» 4 сәг тә — 320 км, «Ока» 10 сәг тә 600 км юл үткән. Кайсының тизлеге зуррак?

459 Поезд 6 сәг тә 366 км юл үткән. Поездның тизлеге автобусның тизлегеннән сәгатенә 19 км га кимрәк. Автобусның тизлеген тап.

460 КамАЗ машинасы 7 сәг тә — 630 км, җиңел машина шул ук араны 5 сәг тә үткән. Җиңел машинаның тизлеге күпмегә артыграк?

Тизлек — вакыт берәмлеге эчендә җисем үткән юл озынлыгы ул.

Юл формуласы.

461 Тизлеге 50 км/сәг булган автомашинаның 2, 3, 4, 7 сәг тә үткән юлын санлы турыда күрсәт һәм таблицага яз.



Вакыт (t)	2	3	4	7
Юл (s)				

462 Әгәр җисемнең хәрәкәт итү тизлеге v булса, аның t вакыт эчендә үткән юлы s ны ничек табарга?

463 $s = v \cdot t$ формуласын кулланып, таблицаны тутыр.

s	v	t
?	60 км/с	3 сәг
120 км	?	4 сәг
42 км	7 м/мин	?

464 Җайдак 11 км/сәг тизлек белән барса, 3 сәгтә ул күпме юл үтәр?

465 Бал корты 6 м/с тизлек белән оча. 180 м ераклыктан ул оясына күпме вакытта кайтып җитәр?

466 Ике шәһәр арасы 240 км. Автобус 70 км/сәг тизлек белән бара. Шәһәрләр арасын ул 4 сәгтә үтә алырмы?

Ераклашу тизлеге.

467

K шәһәреннән бер үк вакытта капма-каршы юнәлештә автобус һәм җиңел машина кузгалып китә. Автобус — 60 км/сәг, җиңел машина 90 км/сәг тизлек белән бара. 3 сәгатьтән аларның арасы ничә километр булыр? (Төрле ысуллар белән исәплә.)

468 Ике велосипедчы бер үк вакытта капма-каршы юнәлештә *A* һәм *B* пунктларыннан кузгалып китә. *A* һәм *B* арасы 44 км. Бер велосипедчы — 15 км/сәг, икенчесе 18 км/сәг тизлек белән бара. 2 сәгатьтән аларның арасы ничә километр булыр?

469 Бер үк вакытта тукталыштан капма-каршы юнәлештә ике автомашина юлга чыккан. Берсенең тизлеге — 60 км/сәг, икенчесенеке — 70 км/сәг. Ничә сәгатьтән соң аларның арасы 520 км булыр?

470 Ильяс белән Илнур бер үк вакытта бер урыннан капма-каршы юнәлештә йөгереп китәләр. Ильяс — 4 м/с, Илнур 6 м/с тизлек белән йөгерә. 40 с тан аларның арасы ничә метр була?

471 Схема буенча мәсьәлә төзе һәм чиш.

472 Тигезләмә буенча мәсьәлә төзе.

$x \cdot 5 + 17 \cdot 5 = 135$

Якынаю тизлеге.

473



Арасы 450 км булган *A* һәм *B* шәһәрләреннән бер үк вакытта кара-каршы ике машина юлга чыга. Берсе — 90 км/сәг, икенчесе 60 км/сәг тизлек белән бара. Алар ничә сәгатьтән соң очраша? 90 + 60 = 150 (км/сәг) аңлатмасы нәрсә аңлата?

474 *A* һәм *B* пунктларының арасы 270 км. Алардан бер үк вакытта кара-каршы чыгып киткән автобуслар 2 сәг тән соң очраша. Автобусларның берсе сәгатенә 60 км юл үтсә, икенчесе нинди тизлек белән барган?

475 Схема буенча мәсьәлә төзе.



476 Җайдак 20 км/сәг тизлек белән авылдан шәһәргә китә. Шул ук вакытта аңа каршы шәһәрдән 60 км/сәг тизлек белән автобус чыга. Алар 2 сәг тән соң очраша. Авыл белән шәһәр арасы ничә километр?

477 Бер шәһәрдән бер үк вакытта капма-каршы юнәлештә ике машина чыгып китә. Аларның берсе — 60 км/сәг, икенчесе 70 км/сәг тизлек белән бара. Ничә сәгатьтән соң аларның арасы 650 км булыр?

478 Казан белән Яр Чаллы арасы 227 км. Бер үк вакытта кара-каршы ике автобус юлга чыга. Казаннан чыгучы автобус — 80 км/сәг, Яр Чаллыдан чыккан автобус 72 км/сәг тизлек белән бара. Очрашканда автобусларның кайсы Казанга якынрак була?

Бер үк юнәлештәге хәрәкәт.
(Артта калу.)

479 Автобус кузгалып 100 м киткәч, Шамил анда түбәтәе калганын исенә төшерә һәм 140 м/мин тизлек белән автобус артыннан йөгерә башлый. Автобусның тизлеге 960 м/мин була. Шамил автобусны куып җитә аламы? 3 минуттан Шамил автобустан нинди ераклыкта була?
960 – 140 = 820 (м/мин) нинди тизлекне аңлата?

480 Хәйдәр Хәмитне 420 м га узгач, Хәмит аның артыннан йөгерә башлый. Хәмитнең тизлеге — 200 м/мин, ә Хәйдәрнеке 300 м/мин булса, 6 минуттан аларның арасы ничә метр була?

481 Бер үк юнәлештәге хәрәкәткә мәсьәлә төзе. Тизлекләре һәм вакыт бирелгән булсын.

482 Ике куян оядан чыгып, бер-бер артлы чабып киткән. Берсенең тизлеге — 480 м/мин, икенчесенең — 530 м/мин. 10 минуттан аларның арасы күпме булыр?

483 Схема буенча мәсьәлә төзе.



484 Мәсьәлә төзе һәм чиш.



Бер үк юнәлештәге хәрәкәт. (Куып җитү.)

485 Төлке куян артыннан 12 м/с тизлек белән йөгерә. Әле аларның арасы 60 м. Куянның тизлеге 9 м/с. Төлке куянны куып җитәрме? Ничә секундтан?
12 – 9 = 3 (м/с) нәрсәне аңлата?

486

Нияз белән Гаяз арасындагы ераклык 300 м булганда, Нияз Гаязны күреп кала һәм 150 м/мин тизлек белән аның артыннан бара башлый. Гаязның тизлеге 100 м/мин булса, малайлар ничә минуттан очрашыр?

487

Бер үк юнәлештәге хәрәкәткә мәсьәлә төзе. Очрашу (куып җитү) вакытын табарга кирәк булсын.

488

Мәсьәлә төзе һәм чиш.



489

Иртәнге сәгать 5 тә пассажир поезды белән йөк поезды арасы 100 км була. Пассажир поезды йөк поездын сәгать 12 гә кадәр куып җитәрме? Пассажир поездының тизлеге — 90 км/сәг, йөк поездының — 70 км/сәг.

490 Схема буенча якынаю тизлеген һәм очрашу вакытын тап.



491 Автомобиль бер минутта 2 км юл үтә. Ул бер сәгатьтә күпме юл үтәр? Автомобильнең тизлеге күпме?

492 Поездның тизлеге 1 100 м/мин. Поездның тизлеген км/сәг белән күрсәт.

493 Машина 1 сәг тә 60 км юл үткән. Машинаның тизлеген м/мин һәм м/сәг белән яз.

494 Автомашинаның тизлеге 600 м/мин. Аны км/сәг белән күрсәт.

495 Автомобильнең тизлеге 15 м/с. Аңа 432 км араны үтәргә күпме вакыт кирәк?

496 Җайдак 90 км араны 6 сәг тә узган. Тизлеге җайдакныкына караганда 5 км/сәг кә кимрәк булган велосипедчы ул араны күпме вакытта үтәр?

497 Аралары 38 км булган ике авылдан бер-берсенә каршы ике велосипедчы чыккан һәм алар 1 сәг тән соң очрашканнар. Бер велосипедчының тизлеге 300 м/мин булса, икенчесенең тизлеге күпме булган?

498 Аралары 480 км булган ике станциядән бер үк вакытта кара-каршы ике поезд юлга чыга, һәм алар 3 сәг тән соң очрашалар. Әгәр бер поездның тизлеге икенчесенекеннән 10 км/сәг кә артыграк булса, һәр поездның тизлеге күпме?

499 Юл буйлап бер-берсенә каршы велосипедчы һәм җәяүле киләләр. Җәяүленең тизлеге — 5 км/сәг, велосипедчының — 12 км/сәг. Хәзерге вакытта аларның арасы 68 км. Алар ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

500 Ике шәһәр арасы 618 км. Бер үк вакытта ике автомобиль бер-берсенә каршы юлга чыгалар. Берсе — 55 км/сәг, икенчесе 48 км/сәг тизлек белән бара. 4 сәгатьтән соң аларның арасы ничә километр булыр? Алар ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

501 Велосипедчы 48 км араны 3 сәг тә үтә. Әгәр тизлеген 4 км/сәг кә киметсә, шул ук араны ул ничә сәгатьтә үтәр?

502 Исәплә.

18 457 − 8 683 : (100 − 81)
3 976 : 28 + 2 816 : 11

503 Бер үк тукталыштан ике велосипедчы капма-каршы юнәлештә юлга чыга. Бер велосипедчының тизлеге — 13 км/сәг, икенчесенең — 15 км/сәг. Беренче велосипедчы юлга икенчесеннән бер сәгатькә соңрак чыккан. Беренче велосипедчы кузгалып күпме вакыт үткәч, аларның арасы 155 км булыр?

504 Бер станциядән бер үк вакытта ике поезд капма-каршы юнәлештә юлга чыккан. Бер поездның тизлеге — 60 км/сәг, икенчесенеке — 70 км/сәг. 4 сәгатьтән соң поездларның арасы ничә километр булыр?

505 Югарыдагы мәсьәләнең соравын үзгәртеп, яңа мәсьәлә төзе.

506 Югарыдагы мәсьәләнең бер шартын үзгәртеп, яңа мәсьәлә төзе.

507 Аралары 900 м булганда, Мөнир җәяү баручы Гөлсинә артыннан велосипедта чыга. 6 мин тан соң ул Гөлсинәне куып җитә. Әгәр Гөлсинәнең тизлеге 90 м/мин булса, Мөнирнең тизлеге күпме булган?

508 Исәплә.

3 348 : 27 + 252 · 50
(1 578 − 19 652 : 34) : 25

Елгадагы хәрәкәт.

509 Моторлы көймә елгадагы ике тукталыш арасын барганда — 3 сәг тә, кайтканда 5 сәг тә үткән. Көймәнең үз тизлеге 16 км/сәг. Ни өчен бару һәм кайту вакыты төрлечә?

510 Елганың агым тизлеге 3 км/сәг. Көймәнең үз тизлеге (акмый торган суда) 7 км/сәг. Көймәнең агымга каршы бару тизлеген санлы турыда күрсәт.



511 Көймәнең агымга каршы тизлеге 18 км/сәг. Елганың агым тизлеге 4 км/сәг. Көймәнең үз тизлеге күпме?

512 Көймәнең агым уңаена бару тизлеге 20 км/сәг. Елганың агым тизлеге 3 км/сәг. Көймәнең агымга каршы тизлеген тап.

513 14 км/сәг, 18 км/сәг, 16 км/сәг — көймәнең агым уңаена, агымга каршы һәм үз тизлеген белдерсә, 18 км/сәг нәрсәне аңлата?

514 Елганың агым тизлеген ничек табып була?

515 Санлы турыда көймәнең агымга каршы һәм агым уңаена тизлеге күрсәтелгән. Елганың агым тизлеге күпме? Аны санлы турыда күрсәт.



516 «Ракета»ның үз тизлеге 50 км/сәг. Елганың агым тизлеге 4 км/сәг. Бер үк вакытта капма-каршы юнәлештә ике «Ракета» тукталыштан кузгалып китә. 3 сәгатьтән соң алар арасындагы ераклык күпме булыр?

517 Елганың агым тизлеге 80 м/мин булса, кузгалып 5 минуттан соң көймә ничә метр юл үткән булыр? (Төрле очракларны кара.)

518 Моторлы көймә 6 сәг тә агым уңаена 180 км юл үтте. Әгәр агым тизлеге 5 км/сәг булса, көймәгә кире әйләнеп кайту өчен, ничә сәгать вакыт кирәк?

519 Елгадагы хәрәкәткә мәсьәлә төзе һәм чиш. Агымга каршы тизлекне табарга кирәк булсын.

520 ? билгесе урынында көймәнең үз тизлеге булса, елганың агым тизлеге күпме?

521 Мәсьәләләрне чиш.

1) Автомобиль 4 сәг тә 360 км юл үткән. Аның тизлеген тап.
2) 4 көндә 360 кг алма җыйганнар. 1 көндә ничә килограмм алма җыйганнар?
3) 4 самоварны 360 долларга сатып алганнар. 1 самовар күпме тора?
Ни өчен бу өч мәсьәлә бергә бирелгән?

522 Ике эшче бертөрле детальләр ясаганнар. Аларның берсе сәгатенә — 11 деталь, икенчесе 15 деталь ясаган. Ике эшче бергәләп 182 детальне ничә сәгатьтә ясар?

523 Бер станок-автомат минутына — 25 деталь, икенчесе 36 деталь ясый. 1 098 детальне алар икесе бергә ничә минутта ясарлар?

524 Автомашиналарның берсе бер рейста — 15 т, икенчесе 12 т йөк ташый. Алар 108 т йөкне икесе бергә ничә рейста ташып бетерерләр?

525 Бергәләп, эш турында мәсьәлә төзегез.

526 Чишелеше буенча мәсьәлә төзе.

360 : (360 : 18 + 360 : 9)

527 Поезд 243 км араны — 3 сәг тә, автобус 272 км араны 4 сәг тә үтә. Кайсының тизлеге зуррак һәм күпмегә?

528 1 кг шикәрнең бәясе a сум. x кг шикәр өчен y сум түләгән булсалар, $y : x$ аңлатмасы нәрсәне аңлата?

529 Таблица буенча мәсьәлә төзе.

Товарның бәясе	Товарның үлчәме	Товарның кыйммәте
300 сум	2 м	?
50 сум	5 кг	?
?	4 $м^2$	600 сум
40 сум	?	800 сум

530 «Бәя», «кыйммәт», «үлчәм» зурлыклары белән 140 : 7 аңлатмасы буенча мәсьәлә төзе.

531 Югарыдагы зурлыклар белән 120 · 4 аңлатмасы буенча мәсьәлә төзе.

532 Бәясе a сумнан b кг җимеш сатып алдылар. Сатып алган җимешнең кыйммәтен тап.

Товарның кыйммәте товар бәясе белән аның үлчәменең тапкырчыгышына тигез.

533 240 т йөкне бер машина — 12 көндә, икенчесе 24 көндә ташый ала. Икесе бергә алар бу йөкне ничә көн ташырлар?

534 Балалар бакчасына уенчыклар алу өчен, 240 доллар акча биргәннәр. Ул акчага 12 курчак яки 24 машина алып була. Курчак һәм машиналарны тигез санда алсалар, барысы ничә уенчык алганнар?

535 Ике тукталыш арасы 240 км. Бу араны бер көймә — 12 сәг тә, икенчесе 24 сәг тә үтә ала. Әгәр көймәләр ике тукталыштан бер үк вакытта кара-каршы чыксалар, алар ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

536 «Ракета» 45 км/сәг тизлек белән 2 сәг күл буйлап, аннан соң шул күлгә коя торган елга буйлап 3 сәг барган. Елга агымының тизлеге 4 км/сәг булса, «Ракета» күпме юл үткән?

537 Автомобильнең тизлеген 15 км/сәг кә киметкәч, ул 60 км/сәг тизлек белән барган. Автомобиль башта нинди тизлек белән барган?

538 Илдар автобуска утырып, 60 км барган. Бу аның җәяүләп барган юлыннан 6 тапкыр күбрәк. Илдар барысы ничә километр юл узган?

539 Ике авыл арасы 48 км. Бу араны Хәмит велосипедта — 12 км/сәг, Рөстәм 16 км/сәг тизлек белән үткән. Малайларның кайсысы юлда озаграк булган?

540 Югарыдагы мәсьәләгә тагын бер сорау өстә.

541 Поезд ике тәүлек барган. Беренче тәүлектә ул — 1 050 км, ә икенче тәүлектә 60 км га кимрәк юл узган. Поезд ике тәүлектә ничә километр юл үткән?

542 Югарыдагы мәсьәләгә тагын бер шарт өстәп, яңа мәсьәлә төзе.

543 Төзелешкә 24 000 кирпеч кирәк. Аны бер машина — 6 рейста, икенчесе 3 рейста китерә ала. Бу кирпечне алар икесе бергә ничә рейста китерерләр?

544 Югарыдагы мәсьәләнең ике шартын үзгәртеп, яңа мәсьәлә төзе.

545 Ике авыл арасы 24 км. Алардан сәгать 9 да капма-каршы юнәлешләрдә ике велосипедчы юлга чыга. Аларның берсе сәгатенә — 12 км, икенчесе 14 км юл үтә. Сәгать 11 дә алар арасындагы ераклык күпме булыр?

546 Капма-каршы хәрәкәткә мәсьәлә төзе.

547 Ике шәһәр арасы 240 км. Бу араны 3 сәг тә үтү өчен, автомобильнең тизлеге нинди булырга тиеш?

548 360 : 5 аңлатмасы белән чишелерлек итеп, хәрәкәткә мәсьәлә төзе.

549 Велосипедчы бертөрле тизлек белән 3 сәг бара. Шуннан соң, тагын 3 км баргач, аның үткән юлы 45 км булган. Тизлекне тап.

550 50 · 4 + 15 аңлатмасы белән чишелә торган мәсьәлә төзе.

551 Балта остасы көненә — 6 ишек, ә өйрәнчек 3 ишек ясый. Алар икесе бергә 54 ишекне ничә көндә ясарлар?

552 Тиз йөрешле көймә 50 км/сәг тизлек белән күлгә коючы елга буйлап — 2 сәг, аннан соң күл буйлап, 3 сәг барган. Елга агымының тизлеге 4 км/сәг булса, көймә күпме юл үткән?

553 Җиңел машина — 90 км/сәг, ә йөк машинасы 60 км/сәг тизлек белән бер үк юнәлештә баралар. Хәзер җиңел машина 45 км га артта. 2 сәгатьтән соң аларның арасы күпме булыр?

554 Гамәлләрне башкар.

(2 052 : 19 − 48) : 12
(964 + 103 · 12) : 110

555 Артта калып хәрәкәт итүгә мәсьәлә төзе.

556 Сәгать 12 дә станциядән чыгып киткән поезд 80 км/сәг тизлек белән бара. 14 сәг тә шул ук станциядән 70 км/сәг тизлек белән икенче поезд аның артыннан чыга. Шул ук көнне 16 сәгатьтә аларның арасы күпме булыр?

557 Ике шәһәр арасы 240 км. Алмаз тизлеге 60 км/сәг булган автобус белән барган. Тизлеге 80 км/сәг булган автомобильдә кайткан. Алмазга бер шәһәрдән икенчесенә барып кайту өчен, юлга күпме вакыт кирәк булган?

558 Көймәнең агым уңаена тизлеге 24 км/сәг. Агым тизлеге 4 км/сәг булса, көймәнең үз тизлеген һәм агымга каршы тизлеген тап.

559 Бер үк юнәлештәге (куып җитү) хәрәкәткә мәсьәлә төзе һәм чиш.

560 Эшче беренче көнне — 32 деталь, икенче көнне 3 детальгә күбрәк, ә өченче көнне беренче көндәгедән 4 детальгә азрак ясаган. Өч көндә эшче барысы ничә деталь ясаган?

561 Бер үк юнәлештәге (артта калып) хәрәкәткә мәсьәлә төзе һәм чиш.

562 Гамәлләрне башкар.

$(16\,884 : 21 - 604) \cdot 31$

$(13\,414 : 19 - 206) : 5$

6 ГЕОМЕТРИК МАТЕРИАЛ

563 Ике фигураның мәйданын ничек чагыштырып була?

564 Фигураларның мәйданнарын чагыштыр. Ничек чагыштырдың?



565 Мәйданнар тигезме? Ничек белдең?



566 Мәйданнарны чагыштыр.



567 Мәйданнарны ничек чагыштырып була?



Ягы 1 см булган квадратның мәйданы 1 квадрат сантиметрга тигез. Квадрат сантиметр кыскартып болай языла: кв.см яки $см^2$.

568 Ягы 2 см булган квадратның мәйданы ничә квадрат сантиметр?

Турыпочмаклыкның мәйданы.

569 Бер үк фигураның мәйданын үлчәү нәтиҗәләре ни өчен төрле булган?



10 квадрат берәмлек



40 квадрат берәмлек

570 Мәйдан үлчәү берәмлеге итеп, 1 $см^2$ алынган. Бирелгән фигураларның мәйданнарын исәплә.



571 Фигураларның мәйданын һәм периметрын тап. Кирәкле үлчәүләрне үзең яса.



572 Ягы 1 дм булган квадратны квадрат сантиметрларга бүлгәлә. Ничә квадрат сантиметр булды? Ягы 1 м булган квадратта ничә квадрат дециметр булыр?

Мәйдан үлчәү берәмлекләрен исеңдә калдыр!

$$1\ мм^2 \xrightarrow{\times 100} 1\ см^2 \xrightarrow{\times 100} 1\ дм^2 \xrightarrow{\times 100} 1\ м^2$$

$$1\ м^2 \xrightarrow{\times 100} 1\ ар \xrightarrow{\times 100} 1\ га$$

1 ар — ягы 10 м булган квадратның мәйданы.
1 гектар (га) — ягы 100 м булган квадратның мәйданы.

573 Буш шакмакларга саннар яз.

$3\ м^2 = \square\ дм^2$

$12\ дм^2 = \square\ см^2$

$20\,000\ мм^2 = \square\ дм^2$

$4\,000\,000\ дм^2 = \square\ м^2 = \square\ ар = \square\ га$

Турыпочмаклыкның мәйданын табу формуласы.

574 Турыпочмаклыкның мәйданын m, n, e үлчәмнәре белән исәпләп яз. Ничек исәпләдең?



575 Турыпочмаклыкның буе a, иңе b. Мәйданын тап.

576 Бүлмәнең буе 8 м, иңе 6 м. Идәнгә җәю өчен, ничә квадрат метр такта кирәк?

577 Квадрат формасындагы катыргының ягы 6 см. Аны ничә квадрат сантиметрга бүлеп була?

578 Бер квадрат сыз. Мәйданы 4 тапкыр зуррак булган тагын бер квадрат төзе.

579 Ягы 40 мм булган квадратның мәйданын һәм периметрын исәплә.

580 Фигураның мәйданын төрле юллар белән исәплә.



581 Фигураның мәйданын квадрат метрларда исәплә.



582 Буялган мәйданнарның кайсы зуррак?





583 Квадратның ягын 10 тапкыр озынайтсаң, аның мәйданы ничек үзгәрер?

584 Буе иңеннән 2 тапкыр озынрак булган турыпочмаклыкның иңе генә сызылган. Турыпочмаклыкны төзеп бетер.



585 Квадратның ягы ничә сантиметр икәнен табу өчен, бер генә сорауга җавап алу да җитә. Ул нинди сорау?

586 Турыпочмаклык формасындагы ике бакчаның мәйданнары тигез. Берсенең буе — 60 м, иңе — 20 м. Икенчесенең иңе — 30 м. Буе күпме? Бакчаларның периметрын тап. Кайсының периметры зуррак, күпмегә?

587 Турыпочмаклыкның периметры — 72 м. Аның иңе буеннан 2 тапкыр кечерәк. Турыпочмаклыкның мәйданын тап.

588 Турыпочмаклык формасындагы бакчаның буе — 125 м, иңе 33 м га кыскарак. Бакчаның мәйданы ничә ар?

589 Фигураның мәйданын исәплә.



590 Турыпочмаклык формасындагы мәйданчыкның иңе 42 м, ә мәйданы 3 948 $м^2$. Аның буе ничә метр?

591 Турыпочмаклыкны дүрт тигез өлешкә бүл. Мәсьәләнең ике чишелешен тап.



592 Турыпочмаклыкның буе иңеннән 6 тапкыр озынрак. Аның периметры 2 940 см. Якларын тап.

593 Ике кишер түтәленең мәйданы — 40 $м^2$. Алардан 160 кг уңыш җыйганнар. Әгәр түтәлнең берсе 6 $м^2$ га зуррак булса, һәр түтәлдән күпме кишер җыеп алганнар? Мәсьәләне төрле юллар белән чиш.

594 Дүртпочмакның мәйданын исәплә.



595 Өчпочмакларның мәйданын исәплә.



596 Бирелгән тимерчыбыктан ничек итеп квадрат ясарсың?

597 Бер үк озынлыктагы 12 таякчыктан 5 квадрат төзе.

598 Тәрәзәнең биеклеге — 1 м 7 дм. Шундый өч тәрәзәнең мәйданы күпмегә тигез?

599 Квадрат формасындагы ишегалдын әйләндереп алган койманың озынлыгы — 120 м. Ишегалдының мәйданын тап.

600 Дәфтәреңдә
1) яклары 9 см һәм 1 см булган турыпочмаклык сыз;
2) периметры турыпочмаклык периметрына тигез булган квадрат сыз.
Турыпочмаклык һәм квадрат мәйданнарының аермасын тап.

601 Түбәндәге фигураларның мәйданнары билгеле: 4 м²; 25 м²; 8 м². Һәр фигурага туры килгән мәйданны тап.



602 Таблицада квадратның ягы (a), периметры (p), мәйданы (s) бутап язылган. Таблицаны дөресләп яз. △ эчендәге саннар үз урынында калсын.

a	△1	5	4	△3	6	7
p	28	△24	12	16	4	△20
s	25	1	△16	36	△49	9

603 Квадратның ягын 3 тапкыр үзгәртсәң, мәйданы ничек үзгәрә?

Турыпочмаклы параллелепипед.

604 Буе — 40 см, иңе — 30 см һәм биеклеге 20 см булган тартманы рәсемдә күрсәтелгәнчә бәйләр өчен, күпме тасма кирәк? Бәйләү өлешенә 50 см тасма киткән.

605 Ике тартма бирелгән. Кайсының күләме зуррак икәнен ничек белергә?



606 Тирә-юньдә тартма формасындагы әйберләрне тап.

607 Рәсемдә турыпочмаклы параллелепипед сурәтләнгән. «Параллелос» (грекча) — янәшә баручы, «эпидос» — яссылык дигән сүз. Аның өслеге нинди фигуралардан тора?



608 Турыпочмаклыкларның яклары турыпочмаклы **параллелепипедның кабыргалары** дип атала. Аның ничә кабыргасы бар?

609 Турыпочмаклыкларның һәркайсы турыпочмаклы **параллелепипедның кыры** дип атала. Аның ничә кыры бар?

610 Дәфтәрдә турыпочмаклы параллелепипед рәсеме яса. Аның алгы һәм арткы кырларын бер төскә, аскы һәм өске кырларын икенче төскә, калган кырларын өченче төскә буя.

611 Турыпочмаклы параллелепипедның өч үлчәме бар: буе, иңе һәм биеклеге. Өч үлчәме тигез булган турыпочмаклы параллелепипедны ничек атыйлар?

Үлчәме 1 см га тигез булган кубның күләме **куб сантиметр** була. Аны кыскача куб см яки $см^3$ дип тамгалыйлар.

612 Куб сантиметрлардан төзелгән фигураларның күләмен исәплә.





613 Үлчәмнәре буенча күләмнәрен исәплә.



614 Үлчәмнәр a, b, c булганда, күләмен тап.



Исеңдә калдыр!

$$V = a \cdot b \cdot c$$

Турыпочмаклы параллелепипедның күләме аның өч үлчәме тапкырчыгышына тигез.

615 Турыпочмаклы параллелепипед моделе ал. Кирәкле зурлыкларны үлчә һәм аның күләмен исәплә.

616 Үлчәмнәре 7 см, 5 см, 10 см булган турыпочмаклы параллелепипедның күләмен тап.

617 Бүлмәнең буе — 8 м, иңе — 6 м, биеклеге — 3 м. Бүлмәдә ничә м³ һава бар?

618 Куб метрда ничә куб дециметр бар?

Исеңдә калдыр!

$$1\ мм^3 \xrightarrow{\times 1\,000} 1\ см^3 \xrightarrow{\times 1\,000} 1\ дм^3 \xrightarrow{\times 1\,000} 1\ м^3$$

619 Тимердән 3 куб ясаганнар. Берсенең үлчәме — 3 см, икенчесенеке — 4 см, өченчесенеке 5 см булган. Аннары аларны эретеп, бергә кушканнар һәм бер куб ясаганнар. Аның үлчәме күпме?



620 Турыпочмаклы параллелепипед моделендә уртак кабыргалы ике кырны, уртак түбәле өч кырны күрсәт.

621 Бүлмәнең күләме — 144 $м^3$. Буе — 8 м, иңе 6 м булса, аның биеклеге күпме?

622 Беренче тартманың үлчәмнәре: 4 см, 5 см, 6 см, икенчесенеке — 2 см, 6 см, 10 см. Кайсы тартмага кабыргасы 1 см булган кублар күбрәк сыяр?

623 Үлчәмнәре 2 см, 4 см, 8 см булган өч тартмадан параллелепипед ясаганнар. Параллелепипедның үлчәмнәре нинди?

624 Турыпочмаклы параллелепипедның үлчәмнәре 4 см, 6 см һәм 8 см га тигез. Аның күләмен һәм уртак түбәсе булган һәр өч кырының мәйданын тап.

625 Кабыргасы 3 см булган кубны кызыл төскә буяганнар һәм күләме 1 $см^3$ булган кубларга кискәләгәннәр. Барысы ничә куб килеп чыккан? Бер кыры, ике кыры, өч кыры кызыл төстәге һәм бер кыры да буялмаган кублар санын тап.

626 Ягы m булган квадратның периметрын һәм мәйданын табу формуласын яз.

627 Яклары m һәм n булган турыпочмаклыкның периметрын һәм мәйданын табу формуласын яз.

628 Математика китабын ачып куй. Ачылган бер битнең һәм куш битнең периметрын исәплә.

629 Дәфтәр тышының мәйданын исәплә.

630 Ягы 17 м булган квадрат формасындагы җир кишәрлегенең мәйданын исәплә.

631 Турыпочмаклык формасындагы җир кишәрлегенең бер ягы — 23 м, икенче ягы 3 тапкыр озынрак. Җир кишәрлегенең мәйданын исәплә.

632 Яклары 5 см һәм 2 см булган турыпочмаклык сыз. Аннан ягы 2 см булган ничә квадрат кисеп алып була?

633 Яклары 5 см һәм 3 см булган турыпочмаклык сыз. Мәйданын исәплә. Периметры турыпочмаклыкныкына тигез булган квадрат сыз.

634 Югарыдагы турыпочмаклык белән квадратның мәйданнарын исәплә. Кайсының мәйданы зуррак һәм күпмегә?

635 Турыпочмаклык формасындагы кәгазь ал. Аны 4 тигез кисәк килеп чыгарлык итеп бөклә. Килеп чыккан битнең периметры 22 см булса, баштагы битнең периметрын тап. Бөкләү сызыклары рәсемдә штрих белән күрсәтелгән.



636 22 см урынына 33 см ны куеп, югарыдагы мәсьәләне чиш.

637 Яклары 40 м һәм 60 м булган турыпочмаклык формасындагы бакчаны тоташ койма белән әйләндереп алганнар. Койманың биеклеге — 2 м. Койма өчен ничә квадрат метр такта кирәк булган?

638 Ике турыпочмаклык сыз. Берсенең яклары — 6 см һәм 2 см, икенчесенеке — 4 см һәм 3 см. Турыпочмаклыкларның периметрларын һәм мәйданнарын чагыштыр.

639 Турыпочмаклыкның бер ягы — 12 см, икенче ягы 3 см га кыскарак. Мәйданын исәплә.

640 Яклары 8 дм һәм 4 дм булган көзгене квадрат формасындагы ике тигез кисәккә бүлгәннәр. Һәр кисәкнең мәйданын һәм периметрын исәплә.

641 Иңе — 10 мм, буе 6 м булган тасманың мәйданын квадрат сантиметрларда исәплә.

642 Яклары 5 мм һәм 45 мм булган турыпочмаклык сыз. Аннан ягы 5 мм булган ничә квадрат кисеп алып була?

643 Югарыдагы турыпочмаклыктан мәйданы 25 $мм^2$ булган ничә квадрат кисеп алып була?

644 Турыпочмаклык формасындагы бүлмәнең мәйданы — 24 $м^2$. Бер ягы — 6 м. Икенче ягын тап.

645 Сызымдагы өч турыпочмаклыкның да мәйданнарын исәплә.



646 Иңе — 6 м, буе 5 м булган турыпочмаклык формасындагы бүлмәнең идәнен буяр өчен, күпме буяу кирәк булыр? 1 $м^2$ га 300 г буяу кирәк.

647 Иңе — 2 м, буе 68 м булган тукыманың мәйданын исәплә.

648 Ишекнең буе — 2 м, иңе 1 м булса, шундый 29 ишекнең мәйданы күпме?

649 Бер тартманың иңе — 1 м, буе 30 дм, биеклеге 60 дм. Күләмен исәплә.

650 Яклары 6 м һәм 8 м булган турыпочмаклык формасындагы сыйныф бүлмәсенең идәнен буяр өчен, 9 кг 600 г буяу киткән. 1 $м^2$ га ничә грамм буяу тотылган?

651 Квадрат формасындагы җир кишәрлегенең ике ягына 44 м озынлыкта киртә тотылган. Кишәрлекнең мәйданын исәплә.

652 Яклары 2 см һәм 6 см булган турыпочмаклык сыз. Мәйданы шундый ук булган икенче турыпочмаклык сыз.

653 Бер ягы — 18 см, икенче ягы 3 тапкыр кыскарак булган турыпочмаклыкның периметрын исәплә.

654 Торт сала торган тартманың төбе квадрат формасында. Ягы 30 см. Тартманың биеклеге 20 см булса, күләмен исәплә.

655 Яклары 5 см һәм 4 см булган ике квадрат бар. Мәйданнарын чагыштыр.

656 Турыпочмаклыкның буе — 16 см, иңе буеннан 4 тапкыр кыскарак. Периметрын исәплә.

657 Квадратның ягы 6 см. Турыпочмаклыкның мәйданы шул квадратның мәйданына тигез. Турыпочмаклыкның бер ягы 12 см булса, периметры күпме?

658 Периметрлары 20 см булган ике турыпочмаклык сыз.

659 Яклары 3 см һәм 4 см булган турыпочмаклык сыз. Мәйданы шундый булган икенче турыпочмаклык сыз.

660 Гамәлне башкар.

$803 \cdot 251 - 4\,048 : 4 - 200\,540$

661 Тигезләмәләрне чиш.

$x \cdot 6 + 18 \cdot 21 = 414$

$6\,443 - x : 7 = 62 \cdot 97$

662 Дәфтәр битендә (яссылыкта) бер нокта куй. Шул ноктадан 3 см ераклыкта торган 4 нокта билгелә.

663 Дәфтәрдә бер нокта билгелә. Шул ноктадан 2 см ераклыкта урнашкан 6 нокта билгелә. Шундый 60, 600 нокта билгеләп буламы?

664 Яссылыкның бирелгән ноктасыннан бертигез ераклыкта яткан барлык ноклалардан торган фигурага нинди исем бирер идең?

665

Латинча «циркус» түгәрәк дигәнне аңлата. Түгәрәкнең чите нинди фигура була? Аны нинди корал ярдәмендә сызып була?

666

Карбыз, туп кебек әйберләрне **шар** формасында дип әйтәләр. Шар формасындагы тагын нинди әйберләр беләсең? Шарны яссылык белән киссәң, кисемдә нинди фигура була?

667

Шарның өслеген **сфера** дип атыйлар. Сфераны яссылык белән киссәң, нинди фигура барлыкка килә?

668

Дәфтәрдә O ноктасын билгелә. O ноктасына циркульнең энәле очын када. Циркульнең грифельле очын шул нокта тирәсендә әйләндер. Грифель сызган йомык сызык ничек атала?

669

Үзәге O (циркульнең энәле очы кадалган нокта) булган әйләнә сыз. Әйләнәдә A ноктасын билгелә. OA кисемтәсен сыз. OA кисемтәсен **әйләнәнең радиусы** дип атыйлар. Радиусы 25 мм булган әйләнә сыз.

670 Радиусы 3 см булган әйләнә сыз. Әйләнәнең 3 ноктасын үзәге белән тоташтыр.

671 Әйләнәдә *A, B, C, D* нокталарын билгелә. Аларны әйләнәнең үзәге белән тоташтыр. *OA, OB, OC, OD* кисемтәләренең кайсы озынрак?

672 Әйләнәнең ике ноктасын үзәк аша үтүче кисемтә белән тоташтыр. Ул кисемтәнең озынлыгын радиус озынлыгы белән чагыштыр.

673 Әйләнәнең ике ноктасын үзәк аша тоташтыручы кисемтәне **әйләнәнең диаметры** дип атыйлар. Радиус диаметрдан күпмегә кечерәк?

674 Яссылыкның әйләнә белән чикләнгән өлешен **түгәрәк** дип атыйлар. Түгәрәккә әйләнә үзе дә керә. Әйләнәнең үзәге, радиусы түгәрәкнең дә үзәге һәм радиусы була. Радиусы 3 см булган түгәрәк сыз.

675 Радиусы 2 см булган түгәрәк сыз. Түгәрәкнең диаметрын үткәр. Түгәрәкнең өлешләрен төрле төсләргә буя.

676 Түгәрәкнең өлешләрен төрле төсләргә буяп, орнамент яса.



7 КАБАТЛАУ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР

677 Төрле радиуслы түгәрәкләр ярдәмендә орнамент яса.



678 Орнаментта нинди фигуралар бар?



679 Өчпочмак һәм квадратлардан торган орнаментка түгәрәкләр өстә.



680 Орнаментны төрле төсләргә буя.



681 Орнаментны ясап бетер.



682 Өчпочмаклар һәм түгәрәкләрдән торган орнамент яса.

683 Квадратлар һәм түгәрәкләрдән торган орнамент яса һәм буя.

684 Үзең теләгән орнамент яса.

685 Орнамент ничек ясалган? Дәфтәргә яса һәм дәвам ит.



686 Орнаментны ясау ысулын тап һәм дәфтәргә күчер.



687 Дәфтәргә күчереп эшлә. Дәвам ит.



688 Күчереп эшлә. Төрле төсләргә буя.



689 Өчпочмак һәм түгәрәкләрдән торган орнамент ясa һәм буя.

690 Өчпочмак һәм квадратлардан торган орнамент ясa һәм буя.

691 Гамәлләрне башкар.

530 + 220 + 70 + 180
454 + 133 + 67 + 46

692 Исәплә.

16 405 + 242 395 40 308 – 8 888

693 Гамәлләрне башкар.

(930 – 900 – 30) + (740 – 740)
(490 + 70 + 110) – (98 – 46 – 46)

694 Мисалларның җавабын тап.

(40 700 – 843) + (7 000 – 6 857)
(70 363 + 4 728) + (36 691 – 1 600)

695 Исәплә.

90 000 – (21 938 + 18 062)
77 777 – 69 999 + 42 222

696 8 888 һәм 6 666 саннарының суммасына 4 446 ны куш.

697 Исәплә.

(68 · 2 – 80) ·14 (1 164 – 13 · 38) · 67

ЭЧТӘЛЕК

1. 1 000 эчендә гамәлләр (Кабатлау) 3
2. Күбурынлы саннар 21
3. Күбурынлы саннарны тапкырлау һәм бүлү 39
4. Тигезләмәләр 72
5. Хәрәкәткә мәсьәләләр 83
6. Геометрик материал 108
7. Кабатлау өчен күнегүләр 132

Учебное издание

Казыханова Фаузия Гиниятовна
Казыханов Виль Суфиянович

МАТЕМАТИКА

Экспериментальный учебник для 3 класса
четырёхлетней начальной татарской школы

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Казыйханова Фәүзия Гыйниятовна
Казыйханов Вил Суфиянович

МАТЕМАТИКА

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
3 нче сыйныфына сынап карау өчен дәреслек

Редакция мөдире *Л. Х. Мөхәммәтҗанова*. Редакторы *Л. Р. Хафизова.*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина.* Тышлык рәссамы *Л. С. Золондинова.*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Р. М. Галимова.*
Корректоры *А. М. Закирова*. Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләре
Э. Ф. Нурмөхәммәтова, Л. Р. Вафина.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.11. 2005. Форматы 70×90 1/16.
Офсет кәгазе. «Прагматика» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 9,95.
Тиражы 3000 д. Заказ К 5/270.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843)292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.



479
x
305
2395
+
1437
146095
1281
x
25
6405
+
2562
32025
162
x
109
1458
+
162
17658
12
?
20
5
9
?
?
16
27
3 см
+
4 см
+
5 см
=
? см
6
7
1
6
6
2
6
8
2